ЧӘРШӘМБЕ
3 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 2 (5802)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы Башкарма Комитеты органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ВУЗ ларда МАРКСИЗМ—ЛЕНИНИЗМ ФӘНЕН УКЫТУНЫ ТАГЫН ДА ЯХШЫРТЫЙК

1938-39 нчы уку елы Советлар Союзындагы барлык югары уку йортлары өчен тарихи ел булды. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгуы һәм шул уңай белән ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда турындагы карары социалистик интеллигенцияне һәм 600 меңле студентлар армиясен идея-политик яктан тәрбияләүне тагын да яхшырту өлкәсендә көчле корал булдылар. Югары уку йортларында марксизм-ленинизм теориясен укытуда нигез итеп „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ алынды һәм бу, марксизм белән ленинизм арасындагы зарарлы өзеклекне бетерүдә гаять зур чара булды. Бу өзеклек ленинизмны үзенә аерым бер таглимат итеп, марксизмнан аерып, диалектик һәм тарихи материализмнан аерып, партия тарихыннан аерып укытудан гыйбарәт иде. Ленинизмның марксизм нигезендә үскәнлеген һәм киңәйгәнлеген, ленинизмның нигезе марксизм икәнлеген, ленинизмның бу нигезен яхшы белми торып, ленинизмны аңлау мөмкин түгеллеген онытудан гыйбарәт иде.

Ленинизмның, диалектик һәм тарихи материализмның аерым курслары урнына, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел 14 нче ноябрь карары нигезендә, югары уку йортларында бердәм курс—марксизм-ленинизм нигезләре курсы оештырылды. ВКП(б) Үзәк Комитеты карарына кадәр диалектик һәм тарихи материализм буенча, ленинизм буенча һәм ВКП(б) тарихы буенча аерым яшәп килгән кафедралар урнына югары уку йортларында бердәм кафедра—марксизм-ленинизм кафедрасы төзелде. ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан күрелгән бу чаралар югары уку йортларында марксизм-ленинизмны укыту эшләрен тиешле дәрәҗәгә күтәрүдә гаять зур роль уйнадылар. Югары уку йортлары елдан артык вакыт эчендә марксизм-ленинизм фәнен укыту эшендә зур уңышларга ирештеләр, бай тәҗрибә тупладылар.

Студентларның һәм профессор-укытучыларның дөньяга карашлары тагы да киңәйде, политик активлыклары тагын да үсте. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар кампаниясендә укытучыларның һәм студентларның актив катнашулары моны бик ачык күрсәтте. Студентлар һәм укытучы-педагоглар арасында марксизм-ленинизм теориясен тирәнтен өйрәнүгә яңа дәрт туды, теорияне үзләштерү тырышканда була торган эш икәнлеге бик ачык расланды. Китап өстендә үзлегеннән эшләүнең бай тәҗрибәсе тупланды. Марксизм-ленинизм теориясе буенча өлгереш бик нык күтәрелде. Аерым вузларда „яхшы“ һәм „отлично“ билгесенә укучы студентлар саны 70—80 процентка җитте.

Укытучы-профессорлар үзләренең теоретик белемнәрен арттыруда зур уңышларга ирештеләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, югары уку йортларында марксизм-ленинизм фәне буенча үткәрелә торган лекцияләрнең һәм семинарларның сыйфаты күп яхшырды. Без бу уңышларның барсын да Казандагы югары уку йортлары тәҗрибәсендә бик ачык күрәбез. Марксизм-ленинизм нигезләре курсын укытучылардан Морозов, Мелещенко, Громов, Плакатин һәм башка иптәшләрнең лекцияләрен студентлар һәр вакыт яратып тыңлыйлар. Бу иптәшләрнең лекцияләре идея-политик яктан тирән эчтәлекле, конкрет материалларга бай, теле ягыннан һәр кемгә аңлаешлы, гади булалар. Бу иптәшләр үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә, лекцияләргә кирәкле материалларны туплау һәм үзләренең культура дәрәҗәләрен күтәрү өстендә һәр вакыт тырышып эшлиләр.

Марксизм-ленинизм нигезләре курсын укыту эшендә зур гына уңышлар булу белән бергә, җидди кимчелекләр дә бар әле. Бу кимчелекләрнең иң зурларыннан берсе—кайбер укытучыларның лекцияләре үзләренең эчтәлекләре һәм формалары ягыннан тыңлаучыларны канәгатьләндерерлек булмауда, марксизм-ленинизм теориясенең бөек идеяләрен конкрет фактлар белән, аңлаешлы телдә аңлатып бирә алмауда. Мисальгә медицина институтында марксизм - ленинизм нигезләрен укытучы иптәш Новиковны алырга була. Бу иптәш үзенең лекцияләрендә конкрет материаллардан бик аз файдалана, укытучының теле бик ярлы, матур әдәбияттан бөтенләй диярлек файдаланмый. Лекция һәр вакыт бер тонда, җансыз барганлыктан, тыңлаучыларны бик тиз ялыктыра, лектор аудитория белән хисаплашмый. Иптәш Новиковның лекциясендә кытыршы формолировкалар еш очрыйлар.

Икенче бер җидди кимчелек—Казандагы кайбер югары уку йортларында студентлар арасында дисциплинаның йомшак булуы. Шул ук Медицина институтының шактый сандагы студентлары лекцияләргә һәм семинарларга начар йөриләр. Мәсәлән, иптәш Ханжинның ноябрь аенда булган бер лекциясенә 82 студент урнына беренче сәгаттә бары 55 студент килде, ә 12 студент лекциягә бөтенләй килмәде. Шулай ук Вандюков, Новиков иптәшләрнең лекцияләренә дә аз йөриләр.

Кайбер ВУЗ ларда студентларның дәрескә үзлекләреннән хәзерләнү мәсьәләсе дә һич тә канәгатьләнерлек түгел. Күп кенә студентлар үзлекләреннән хәзерләнмичә тик лекция тыңлау белән генә канәгатьләнеп калалар. Мәсәлән, Педагогия институты студентларыннан Мрачков, Степанов, Фадеева, Ярыгина, Ефремов һәм башка иптәшләр үзлекләреннән бөтенләй диярлек укымыйлар, лекция тыңлау белән генә канәгатьләнеп калалар. Студентларның үзлекләреннән укуларын оештыруда, аларга ярдәм итүдә югары уку йортлары янындагы марксизм-ленинизм кабинетлары ярдәм итәргә тиешләр. Ләкин югарыда күрсәтелгән институтларда бу кабинетлар һич тә канәгатьләнерлек эшләмиләр әле.

Студентларны марксизм - ленинизм теориясе белән—иҗтимагый үсеш һәм политик көрәш законнарын белү белән коралландыру кебек җаваплы эшне үтәүгә партия һәм комсомол оешмалары, ВУЗ ларның дирекцияләре зур игтибар бирергә, моңа кадәр яшәп килгән җитешсезлекләрне якын арада бетерү өчен бөтен чараларны күрергә тиешләр.

„...фәннең бер тармагы бар, аны белү фәннең барлык тармакларындагы большевиклар өчен мәҗбүри булырга тиеш. Ул — җәмгыят турындагы, җәмгыятьнең үсеш законнары турындагы, пролетариат революциясенең үсеш законнары турындагы, социалистик төзелешнең үсеш законнары турындагы, коммунизмның җиңүе турындагы марксизм-ленинизм фәне. Чөнки, үзен ленинче дип атап та үзенең специальностына кереп бикләнгән, әйтик, математикага, ботаникага яки химиягә кереп бикләнгән һәм үзенең специальностыннан ары бер нәрсәне дә күрмәүче кешене чын ленинче дип санап булмый. Ленинче булган кеше фәннең үзе яраткан тармагының гына белгече булып кала алмый,—ул бер үк вакытта үз иленең язмышы белән якыннан кызыксынучы, иҗтимагый үсеш законнары белән таныш, бу законнардан файдалана белүче һәм илгә политик җитәкчелеккә актив катнашырга омтылучы политик булырга — җәмагать эшчесе булырга тиеш“. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның бу күрсәтмәсен бер генә минутка да онтырга ярамый.

Ленинград Хәрби Округы Штабының оператив сводкасы

1 нче гыйнварда фронтта күрсәтерлек әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация күп кенә районнарда уңышлы бомбардировка үткәрде. Һава сугышында дошманның 2 самолеты бәреп төшерелде.

Совет—Япония арасында 1939-елның 31 нче декабрендә төзелгән килешүләр

I.

КВЖД өчен соңгы взносны түләү турында Совет—Япония килешүе

Соңгы вакытларда Япония илчесе Того әфәнде белән Чит Ил Эшләре Халык Комиссары В. Молотов арасында булган сөйләшүләр нәтиҗәсендә КВЖД (Көнчыгыш Кытай тимер юлы) өчен СССР хөкүмәтенә Манчжоу-Го хөкүмәте тарафыннан соңгы взносны түләү турындагы һәм бу хөкүмәтләрнең үзара дәгваларын тәртипкә салу турындагы мәсьәлә буенча һәр ике як түбәндәгечә килешүгә килделәр:

1. Япония хөкүмәте, КВЖД өчен 5.981.625 иена күләмендәге соңгы взносны, алтын клаузуласы буенча (КВЖД турындагы килешүнең VIII нче статьясенең 5 нче пункты) 792.200 иена 64 сена күләмендәге өстәмәне һәм 1938 нче елның 23 нче мартыннан 1940 нчы елның 3 нче гыйнварына кадәр вакыт өчен 5.981.625 иена сумага тиешле булган 320.057 иена 91 сена күләмендәге еллык 3 процентны, барлыгы 7.093.883 иена 55 сена күләмендәге суманың Манчжоу-Го хөкүмәте тарафыннан бик тизлек белән түләнүен СССР хөкүмәтенә тәэмин итә. Бу сумадан Манчжоу-Го хөкүмәте тарафыннан СССР хөкүмәтенә карата 1.284.317 иена 74 сена күләмендәге дәгва ителә торган сума тотып калына.

Шушының нигезендә 1940 нчы елның 4 нче гыйнварында СССР ның Токиодагы илчелегенең агымдагы хисабына Манчжоу-Го хөкүмәте тарафыннан 5.809.565 иена 81 сена кертелә.

2. Манчжоу-Го хөкүмәтенең СССР га карата башка дәгвалары белән берлектә, 1.284.317 иена 74 сена күләмендә 1 нче пунктта әйтелгән дәгвалар, шулай ук СССР хөкүмәтенең Манчжоу-Гога карата башка дәгваләре белән берлектә, КВЖД ның элекке хезмәткәрләренә пенсия сумалары түләү турында Совет тарафыннан Америка доллары белән 590.000 доллар күләмендә итеп исәпләнеп, Советлар союзының Манчжоу-Гога карата куйган дәгвалары Япониянең чит ил эшләре министренең һәм Манчжоу-Гоның Токиодагы илчесенең, шулай ук СССР ның Япониядәге тулы хокуклы илчесенең һәм сәүдә вәкиленең карамагына тапшырылалар.

3. Һәр ике як, Манчжоу-Го хөкүмәте тарафыннан СССР ның Япониядәге тулы хокуклы илчелегенең агымдагы хисабына кертеләчәк суманың кимендә өчтән ике өлеше Япония—Манчжоу-Го товарларын сатып алуга тотылыр дип килештеләр, ләкин ассортимент Совет тарафыннан куелган таләпләргә туры килерлек булырга, ә товарларның сыйфаты һәм бәясе нормаль булырга тиеш дигән шарт куелды.

31 декабрь, 1939 ел.

II.

Балык тоту мәсьәләсе буенча Совет—Япония килешүе

ПРОТОКОЛ

Балык тоту турында Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Япония арасында 1928 нче елның 23 нче гыйнварында кул куелып, 1936 нчы елның 25 нче маенда, шул ук елның 28 нче декабрендә, 1937 нче елның 29 нчы декабрендә һәм 1939 нчы елның 2 нче апрелендә кул куелган протоколлар белән озайтылган конвенциянең срогы 1939 нчы елның 31 нче декабрендә тулганлыктан; һәм

Яңа конвенция 1939 нчы елның 31 нче декабренә кадәр төзелмәячәк булганлыктан;

Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте һәм Япония хөкүмәте түбәндәге статьялар турында килештеләр:

СТАТЬЯ 1.

Балык тоту турында Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Япония арасында төзелгән конвенция, шулай ук 1928 нче елның 23 нче гыйнварында кул куелып аңа теркәлгән документлар 1940 нчы елның 31 нче декабренә кадәр көчләрендә калалар.

СТАТЬЯ 2.

Бу протокол яңа конвенция белән алыштырылырга тиеш. Хәзерге вакытта бу конвенция турында Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте белән Япония хөкүмәте арасында сөйләшүләр алып барыла һәм ул 1940 нчы елны төзеләчәк.

Шушыны таныклау йөзеннән, түбәндә кул куючылар, һәр кайсы үз хөкүмәтләре тарафыннан тиешенчә хокук алган хәлдә бу протоколга кул куйдылар.

Москва шәһәрендә, 1939 нчы елның 31 нче декабрендә, 14 нче Сиов елының 12 нче аеның 31 нче көненә туры килә торган көндә, ике данә итеп төзелде.

Япония илчесе Того әфәндегә Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш Молотовның нотасы

Москва, 31 декабрь 1939 ел.

Илче әфәнде.

Балык тоту турында Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Япония арасында төзелеп, 1928 нче елның 23 нче гыйнварында кул куелган конвенцияне һәм шул ук көнне кул куелып аңа теркәлгән документларны 1940 нчы елга да көчләрендә калдыру турында бүген протоколга кул куелу уңае белән түбәндәгеләр турында Сезгә белдерәм:

1. 11, 12, 13, 14, 18, 19, 21, 22, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 36, 37, 39, 42 нче номерлы консерв заводларыннан һәм аларга беркетелгән 104, 105, 106, 107, 108, 109, 110, 708, 742, 743, 757, 758, 766, 767, 775, 776, 782, 829, 830, 837, 838, 839, 842, 847, 848, 854, 855, 857, 858, 860, 861, 866, 867, 975, 980, 981, 984, 985, 986 нчы номерлы балык тоту участкыларыннан Япония кешеләренең файдаланулары турында 1928 нче елның 3 нче ноябрендә төзелгән махсус договорларны, шул договорларга кагылышлы документларны һәм соңыннан булган өстәмә килешүләрне Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте элекке шартларда ук 1940 нчы елның 31 нче декабренә кадәр яңартырга риза.

2. 1940 нчы елга Совет дәүләт промышленностына лосось нәселеннән булган балыкларны тоту буенча 5.000.000 пот күләмендәге элекке норма биреләчәк.

3. Договорларда күрсәтелгән аренда сроклары 1939 нчы елны тула торган 523, 650, 674, 675, 1205, 1206 һәм 1288 нче номерлы балык тоту участкылары 1940 нчы елны торгига куелачаклар.

4. ССР Союзының Тын океан яры буендагы балык тоту участкыларын арендага алган япон балык промешленниклары, шулай ук консерв заводларыннан һәм аларга беркетелгән балык тоту участкыларыннан файдалану өчен ССР Союзы Хөкүмәте белән махсус договорлар төзегән Япония кешеләре, хәзергә кадәр булган кебек, 1940 нчы елны да Дәүләт Банкысыннан 100 сумлык облигациягә 32,5 иеналык курс буенча АКО облигацияләре ала алачаклар. Бу облигацияләрне Дальрыба тарафыннан, номиналь бәяләре буенча, аренда түләүләре, паушалир налоглар, җыемнар һәм залоглар исәбенә кабул ителәчәк.

Ләкин әгәр дә АКО облигациясе өчен түләү бәясенә туры килә торган һәм 1939 нчы елның 1 нче апреленә Нью-Йоркта алтын бәясе һәм иена курсы нигезендә исәпләнгән саф алтын авырлыгына чагыштырганда АКО облигациясе өчен түләү бәясенә туры килә торган һәм АКО облигациясе өчен түләү көненнән алдагы көндә Нью-Йорктагы алтын бәясе һәм иена курсы нигезендә исәпләнгән саф алтын авырлыгы үзгәрсә, ул чагында АКО облигациясе өчен түләү бәясе саф алтын белән исәпләгәндә 1939 нчы елның 1 нче апреленә ни бәя булса, АКО облигациясе өчен түләү сумасы да шул кадәр үк булырлык итеп тиешенчә арттырылачак яки киметеләчәк.

Шушы хәлдән файдаланып Сезгә карата бөек ихтирамыма ышандыруымны кабатлыйм.

СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссары В. МОЛОТОВ.

* * *

Япония илчесе Того әфәнде үзенең җавап нотасында югарыда китерелгән нотаның эчтәлеген тулысынча кабатлады һәм аны игтибарга алуын белдерде.

СОВЕТ—ЯПОНИЯ АРАСЫНДА 1939 НЧЫ ЕЛНЫҢ 31 НЧЕ ДЕКАБРЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН КИЛЕШҮЛӘР УҢАЕ БЕЛӘН

КВЖД өчен соңгы взносны түләү турында һәм СССР белән Япония арасында 1928 нче елны төзелгән балык тоту конвенциясен 1940 нчы елга озайту турында бүген иглан ителә торган документлар—Япония белән СССР арасында булган дәгвалы мәсьәләләрне тәртипкә салу юлында уңышлы адымнар.

Бу ике килешүне төзү шушы елның ноябрь-декабрь айларында Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш Молотов белән Япониянең Москвадагы илчесе Того әфәнде арасында булган берничә беседаның һәм озакка сузылган сөйләшүләрнең нәтиҗәсе булды. Бу сөйләшүләрнең барсында да Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш Лозовский катнашты. Кул куелган килешүләрнең әһәмияте хәл ителгән мәсьәләләрнең күләменнән һәм характерыннан күренә.

КВЖД ны сату турында 1935 нче елның 23 нче мартында СССР белән Манчжоу-Го арасында төзелгән договор буенча КВЖД өчен 5.981.625 иена күләмендәге соңгы взносны Советлар Союзына Манчжоу-Го хөкүмәте 1938 нче елның 23 нче мартында кертергә тиеш иде. Түләүдән берничә көн элек Манчжоу-Го хөкүмәте СССР Хөкүмәтенә 5.000.000 иенадан артык булган күләмдә каршы дәгва куйды. Совет Хөкүмәте бу дәгваларның нигезсез икәнлеген күрсәтеп, аларны үтәүдән баш тартты. Манчжоу-Го хөкүмәте, үз чиратында, бу дәгваларында нык торып, КВЖД өчен соңгы взносны билгеләнгән срокта түләмәде.

Хәлбуки, КВЖД ны сату турындагы договор нигезендә Япония хөкүмәте КВЖД өчен түләү буенча үзенең өстенә гарантияле йөкләмә алган иде һәм КВЖД өчен түләүнең вактында кертелүен тәэмин итәргә тиеш иде. Япония хөкүмәтенең йөкләмәсе Япониянең элекке тышкы эшләр министре Коки Хиротаның 1935 нче елның 23 нче мартында биргән рәсми нотасында әйтелде. Анда болай диелгән иде:

„Япония белән Манчжоу-Го арасында якын һәм үзләренә бер төрле мөнасәбәтләр булганлыктан Япония хөкүмәте, югарыда әйтелгән килешүнең 7 нче статьясенә ярашлы рәвештә шундый ташлама нәтиҗәсендә Манчжоу-Го хөкүмәтенең Совет Социалистик Республикалар Союзы хөкүмәте каршындагы барлык йөкләмәләрен акчалата да, шулай ук товарлата да югарыда әйтелгән килешүдә күрсәтелгән срокларда төгәл үтәвен гарантияләүне үзенә йөкләмә итеп ала“.

Шушы гарантияле йөкләмәдән чыгып, Совет хөкүмәте 1938 нче елның ноябрендә үк инде, КВЖД өчен соңгы взнос түләнми торып озак срокка балык тоту конвенциясе төзү турындагы сөйләшүләргә керешмәячәген Япония хөкүмәтенә белдергән иде. Манчжоу-Го хөкүмәте дә, гарантияләүче Япония хөкүмәте дә 1938 һәм 1939 нчы еллар эчендә КВЖД өчен соңгы взносны кертмәделәр.

1939 нчы елның көзендә Япония хөкүмәте балык тоту турында СССР белән Япония арасында озак срокка конвенция төзү турындагы мәсьәләне янадан куйды. КВЖД өчен соңгы взнос кертелмәгәнлектән Совет хөкүмәте КВЖД өчен соңгы взнос кертелми торып, үзенең сөйләшүләргә керешмәячәген Япония хөкүмәтенә яңадан белдерде.

Балык тоту мәсьәләсе буенча вакытлы килешүнең срогы 1939 нчы елның ахрында беткәнлектән Япония хөкүмәте балык тоту турындагы конвенцияне 1940 нчы елга гына озайтырга такдим итте. Бу такдимгә Совет хөкүмәте балык тоту турында 1928 нче елгы конвенцияне һәм аның барлык протоколларын 1940 нчы елга озайтырга хәзер торуын, ләкин балык тоту турындагы конвенцияне 1940 нчы елга озайту турындагы протоколга кул кую алдыннан КВЖД өчен соңгы взнос һич шиксез түләнергә тиеш дип санавын белдереп җавап бирде.

КВЖД өчен соңгы взносны кертү турындагы сөйләшүләр 1939 нчы елның 31 нче декабрендә Совет—Япония килешүенә кул кую белән тәмам булдылар. Бу килешүнең тексты бүген иглан ителә.

Бу килешү буенча Япония хөкүмәте Советлар Союзына КВЖД өчен 5.981.625 иена күләмендәге соңгы взносны һәм биржада иенаның бәясе үзгәреп торудан Совет дәүләте интересларын гарантияли торган алтын клаузуласы буенча өстәмә суманы Манчжоу-Го хөкүмәтенең бик тизлек белән түләвен тәэмин итә. Өстәмә суманың күләме 792.200 иена 64 сенага кадәр җитә. Шуның өстенә Совет хөкүмәте 1938 нче елның 23 нче мартыннан түләү көненә кадәр, ягни 1940 нчы елның 3 нче гыйнварына кадәр булган вакыт өчен 5.981.625 иеналык сумага 320.057 иена 91 сена күләмендәге еллык 3 процентны ала.

Манчжоу-Го хөкүмәте үз тарафыннан Совет хөкүмәтенә 1.284.317 иена 74 сена күләмендә каршы дәгвалар куйганлыктан, ә КВЖД ның элекке хезмәткәрләренә 590.000 Америка доллары күләмендә пенсия сумалары түләү турында Манчжоу-Гога Советлар Союзының нигезле дәгвалары булганлыктан, аннан соң Манчжоу-Го хөкүмәтенең СССР га карата тагын башка дәгвалары, ә СССР хөкүмәтенең үз чиратында Манчжоу-Го хөкүмәтенә күп кенә башка дәгвалары булганлыктан, һәр ике як 1.284.317 иена 74 сена күләмендәге суманы Советлар Союзына тиеш булган 7.093.883 иена 55 сена күләмендәге сумадан чигерергә риза булдылар. Манчжоу-Гоның 1.284.317 иена 74 сена күләмендәге дәгвасы, шулай ук Советлар Союзына карата башка дәгвалары һәм Советлар Союзының Манчжоу - Гога карата барлык дәгвалары, шул исәптән КВЖД ның элекке хезмәткәрләре өчен 590.000 Америка доллары күләмендә пенсия сумалары турындагы дәгва Япониянең чит ил эшләре министренең һәм Манчжоу-Гоның Токиодагы вәкиленең, шулай ук СССР ның Япониядәге тулы хокуклы илчесенең һәм сәүдә вәкиленең бергәләп карауларына тапшырылалар.

Шулай итеп, КВЖД өчен соңгы взносны түләү турындагы мәсьәләне тәмам хәл ителгән дип санарга мөмкин һәм Япония—Совет мөнасәбәтләрендә КВЖД га бәйләнешле барлык калган бәхәсләр килешүдә күрсәтелгән юл белән бетерелер дип ышанырга кирәк.

КВЖД өчен соңгы взнос турындагы мәсьәлә хәл ителгәнлектән, балык тоту мәсьәләсе буенча сөйләшүләрне тизрәк төгәлләү өчен уңайлы шартлар тудырылды.

Бүген иглан ителә торган документлардан күренүенчә, Советлар Союзы балык тоту конвенциясен 1940 нчы елга озайтырга риза булып кына калмый, бәлки балык тоту буенча 1940 нчы елны озак сроклы конвенция төзергә дә хәзер торуын белдерә.

Балык тоту конвенциясе 1940 нчы елга озайтылганлыктан 20 консерв заводына һәм аларга беркетелгән 39 участкыга төзелгән аерым договорларны да бер елга озайтырга карар бирелде, үзләренең аренда сроклары 1939 нчы елны тула торган барлык участкылар өчен торги принципы раслана һәм бөтен дөнья акча базарында иенаның бәясе үзгәреп торудан Совет хөкүмәтенә зиан килмәсен өчен түләүләрнең ныклы модусы билгеләнә.

Балык тоту турындагы конвенцияне 1940 нчы елга озайту һәм балык тоту турында тагын да озак срокка конвенция төзү турында сөйләшүләр башлану—СССР белән Япония арасында экономик мөнасәбәтләрнең үсүе юлында җидди һәм яхшы адым. Билгеле, СССР суларында балык промышленникларының нормаль эшләүләре өчен иң кирәкле шарт, аларның договорларны һич сүзсез үтәүләреннән, совет законнарына, балыкларны саклау һәм үрчетү буенча билгеләнгән кагыйдәләргә буйсынуларыннан гыйбарәт.

(ТАСС).

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Авыл хуҗалыгының фәнни работниклары һәм белгечләре киңәшмәсе

31 нче декабрьдә ВКП(б) Өлкә Комитетында авыл хуҗалыгы буенча фәнни работникларның һәм белгечләрнең киңәшмәсе булды. Авыл хуҗалыгы буенча уку йортларының, тәҗрибә-тикшеренү учреждениеләренең, фәнни работникларның, белгечләрнең һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәштә катнашлары турындагы мәсьәлә тикшерелде.

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев киңәшмәне ачып, партия һәм хөкүмәт тарафыннан социалистик игенчелек алдына куелган бурычларны кыскача сөйләде һәм бу бурычларны уңышлы хәл итүдә фәнни работникларның һәм белгечләрнең гаять зур урын тотканлыгын аеруча күрсәтте.

Киңәшмәдә ТАССР Җир Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш Косушкин, дәүләт университетының проректоры иптәш Макаров, Авыл хуҗалыгы институтының директоры иптәш Мостафин һәм аның урынбасары иптәш Вершинин, профессорлардан Тихонов һәм Винокуров иптәшләр, селекция станциясенең фәнни сотрудниклары, Татнаркомзем, Совхозтрест һәм башка оешмаларның һәм учреждениеләрнең белгечләре чыгып сөйләделәр.

Шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире иптәш Саланов һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетының крестьян яшьләре бүлеге мөдире иптәш Вәлиев конкрет тәкъдимнәр белән чыгыш ясадылар. Барлыгы 16 кеше чыгып сөйләде.

Киңәшмәдә катнашучылар һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен Бөтенсоюз күләмендә бара торган социалистик ярышка кушылырга бердәм теләк белдерделәр. Дәүләт университеты, Авыл хуҗалыгы институты, тәҗрибә станциясе һәм башка фәнни, тәҗрибә-тикшеренү учреждениеләре югары уңыш алу буенча практик эш алып бару өчен, үзләренең карамакларына аерым районнар һәм колхозлар алалар. Киңәшмә бу эшкә республиканың тәҗрибә кырларының, авыл хуҗалыгы техникумнарының, районара мәктәпләрнең кушылуларын кирәк дип тапты.

Барлык фәнни һәм тәҗрибә-тикшеренү учреждениеләренең һәм аларның работникларының, шулай ук авыл хуҗалыгы белгечләренең якындагы бурычлары,—кышкы агротехника чаралары планының тулысынча үтәлүе өчен көрәшүдән, язга хәзерлектә колхоз, МТС һәм совхозларга булышлык итүдән, колхозларда стахановчылар мәктәпләре оештыру һәм бу мәктәпләрдә укуларны тиешле юлга салудан, агротехника фәненең һәм алдынгы практиканың казанышларын популярлаштыруудан гыйбарәт.

Киңәшмә ахрында иптәш Матвеев барлык фәнни һәм тикшеренү учреждениеләренең бу эш белән һич кичекмәстән һәм чын-чынлап шөгылләнергә тиешлекләрен күрсәтте. Һава шартларының нинди булуына да карамастан, һәр гектардан 100 пот иген уңышы алуга ирешү өчен, һәр елны 8 миллиард пот ашлык җитештерү турында иптәш Сталин күрсәтмәсен үтәү өчен барлык чараларны күрергә кирәк. Иптәш Матвеев барлык фәнни работникларны һәм авыл хуҗалыгы белгечләрен матбугатта актив катнашырга, алдынгы агротехникларның, хаталабораториядә мөдирләренең һәм стахановчыларының тәҗрибәләрен уртаклашуны оештырырга чакырды.

Киңәшмә махсус комиссиягә 5 нче гыйнвардан да соңга калмыйча фәнни һәм тәҗрибә-тикшеренү учреждениеләре өчен аерым районнарны һәм колхозларны билгеләүне, һәм бу колхозларда һәм районнарда үткәреләчәк чаралар планын ачыкландыруны тапшырды.

Партия оешмасы алдынгылар хисабына үсә

„Урак һәм Чүкеч" заводы (Казан) партоешмасы ВКП(б) сафларына яңа членнар кабул итү эшен шактый көчәйтте. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң 7 кеше ВКП(б) члены итеп һәм 13 кеше кандидат итеп кабул ителде. Хәзер оешмада 52 коммунист хисаплана. Партия сафларына кабул ителгәннәр арасында заводның алдынгы стахановчыларыннан Гайнеттинов, Миңгалиев, Сәйфеттинев, инженер Рыйтов һәм техник Савинкова иптәшләр бар.

Яшь коммунистлар производствода яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. Мәсәлән, шлифовальщик иптәш Яруллин һәм токарь Тохтин иптәшләр, производство планын һәр айны 250—300 процент итеп үтиләр.

Яшь коммунистлардан күп кенә иптәшләр җаваплы эшләргә күтәрелделәр. Элек токарь булып эшләгән стахановчы иптәш Гайнеттинов хәзер механика цехының мастеры булып эшли. Ул җитәкчелек итә торган цех заводта алдынгы булып тора. Строгальщик иптәш Миңгалиев кадрлар бүлеге начальнигы итеп күтәрелде. Җыю цехында бригадир булып эшләгән иптәш Лазарев завком председателе итеп сайланды.

Бу оешмада кимчелекләр дә бар әле. Хатын-кызлар арасында эшләү, аларны партия сафларына тарту эше начар тора. Быел партиягә хатын-кызлардан 3 кенә кеше кабул ителү моны ачык күрсәтә. Заводта эшче һәм хезмәткәр хатын-кызларны җәмагат эшләренә кинрәк тартырга, алар арасыннан иң алдынгыларны партиягә керүгә хәзерләү эшен оештырырга кирәк.

Ш. Шакиров, А Нигматов.

Кадрлар һәм гамсез җитәкчеләр

Бездә кадрлар — партиянең һәм дәүләтнең алтын фонды. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин ВКП(б) ның XVIII нче съездында сөйләгән докладында кадрларга бәя бирә белергә, аларны ихтирам итәргә, үсеп килүче һәрбер работникка югары күтәрелү өчен ярдәм итәргә кирәклекне күрсәтте.

Партиянең бу мәсьәлә турындагы күрсәтмәләрен тормышка ашыру эше Чистай районында начар тора: кадрларга бюрократларча җансыз карау фактлары яшәп килә. Райондагы күп кенә оешмаларда кадрларны һич кирәксезгә бер урыннан икенче урынга күчерү, ныклап тикшермичә эштән алу система булып киткән. Район оешмаларының җитәкчеләре кадрларның интересларына бәйләнгән мәсьәләләрне вактында җидди рәвештә тикшермиләр.

Конкрет фактларга күчик. Күп еллардан бирле совет сәүдәсе өлкәсендә намус белән эшләгән коммунист иптәш Вера Сидорова мәсьәләсен алырга мөмкин. Татреспторгның Чистай бүлеге управляющие Абдуловның бюрократларча эш итүе нәтиҗәсендә ул сентябрь һәм октябрь айларында гына да алты урынга күчерелгән. Абдулов моның белән генә чикләнми, иптәш Сидорова эшкә урнаштыруны сорап килгән саен, ул: „Иртәгә кил, кайда булса да урнаштырырмын, приказ язып куярмын" дип „җылы" вәгъдәләр бирә. Абдулов ахрында үзенең вәгъдәләрен „тормышка ашыру йөзеннән" приказлар язып, аны бер нинди работник кирәк булмаган магазиннарга йөртеп аптырату „методына" күчә. Иптәш Сидорова кайсы гына магазинга приказ күтәреп бармасын, аны: „бездә урын юк" дип кире җибәрәләр.

Абдулов үзенә ошамаган башка коммунистларга карата да шундый „методлар" куллана. ВКП(б) членнары Шишов һәм Титов иптәшләргә карата булган фактларны күрсәтеп үтәргә кирәк. Татреспторг бүлегендәге кимчелекләрне иптәш Титовның кыю рәвештә тәнкыйтьләве Абдуловның кәефенә ошамый. Шуна күрә ул ясалма һәм күпертелгән гаепләр табып, аны эштән ала. Тикшерү нәтиҗәсендә, гаепләүләрнең берсе дә расланмый. Шул тикшерүләрдән соң шактый вакыт үтүгә карамастан, Абдулов аны яңадан бер кайда да эшкә урнаштырмый. Иптәш Шишов белән дә шундый ук хәл булды.

Бу коммунистлар Абдулов мәсьәләсенең принципиаль рәвештә тикшерелүен сорау теләге белән ВКП(б) райкомына киләләр. Кызганычка каршы, алар монда кирәкле ярдәмне ала алмыйлар. Райкомның икенче секретаре иптәш Завьялов: „Ярар карарбыз, Абдуловны чакыртырбыз" дип вәгъдәләр бирү белән чикләнә, аларны айлар буена нәтиҗә көтәргә, эшләмичә йөрергә мәҗбүр итә. Бу факт үзе генә дә райкомның кадрларга ничек гамсез каравын ачык күрсәтеп тора.

Кадрларга җансыз карауны күрсәткән тагын бер факт. Бу факт—коммунист иптәш Екатерина Рябова мәсьәләсе. Ул 1926 нчы елдан бирле ВКП(б) члены. Шәһәрнең икенче балалар йортында директор булып бер ел чамасы эшләгәннән соң аны прогулчыларны яклауда гаеплиләр. Район прокуроры Ляпнев аның өстенә ташланган гаепләрне ныклап тикшермичә эшне судка тапшыра. Бик тиз генә, күргәзмә суд оештыралар. Шул ук прокурор гаепләү речь белән чыга. Иптәш Рябова үзен аклый торган документларны хәзерләргә өлгерә алмавын белдерә һәм аны хәзерләп тапшыру өчен судны берничә көнгә кичектерергә сорый. Ләкин аның соравы белән хисаплашмыйлар, аны 6 айга иркеннән мәхрүм итәргә хөкем итәләр. Иптәш Рябова берничә көннән соң бөтен документларын туплап ТАССР Верховный Судына жалоба яза. Бу эш яңадан тикшерелгәннән соң, ТАССР Верховный Суды район судының карарын юкка чыгара. Шулай да аны җәзасыз калдырырга теләмиләр: „прогулчыларга йомшаклык күрсәткән өчен" дип Рябовага 6 ай мәҗбүри эш бирәләр. Мәсьәләнең аслын конкрет рәвештә ныклап тикшереп карaганда, иптәш Рябованы суд җаваплылыгына тартырлык мотивлар юк.

Иптәш Рябова үзен эштән нигезсез рәвештә чыгарулары турында райкомда һәм Шәһәр Советында сөйләсә дә, аңа игътибарсыз карыйлар. Ахырда ул нинди дә булса эшкә урнаштыруны сорый. Күп йөри торгач 2 нче яслегә мөдир итеп урнаштыралар. Ләкин биредән дә аны эштән алу өчен „мотив" табалар: аның үзенә бәйләнмәгән, бәлки Шәһәр Советы җитәкчеләренә бәйләнгән кимчелекләр буенча эштән чыгаралар.

Районда кадрларның язмышына бәйләнгән шундый фактлар аз түгел. Болар барсы да район җитәкчеләренең бу мәсьәләгә гамсез карауларын, бюрократизмга каршы кискен көрәш алып бармауларын, намуслы коммунистларга ташланган гаепләр белән җидди рәвештә кызыксынмауларын ачык күрсәтәләр.

Партиябез, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин партия оешмаларыннан кадрларны большевизм рухында, түземле рәвештә тәрбияләүне, һәрбер работникның яхшы якларын һәм кимчелекләрен ныклап өйрәнүне таләп итәләр. XVIII нче съездның бу турыдагы күрсәтмәләрен үтәү буенча Чистай районында җидди борылыш булдырылырга тиеш.

К. Исламов.

Бауман район советының яшь депутатлары. РӘСЕМДӘ: Уңнан—С. Аминова (1 нче тегү фабрикасының кадрлар бүлеге мөдире), А. Леонтьев (язу машиналары заводының баш механигы) һәм А. Бешенов (Казан Пехота училищесенең кече командиры). А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фото-хроникасы).

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНДА

1939 нчы елның 31 нче декабрендә иптәш Динмөхәметов председательлегендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының утырышы булды. Президиум Татарстан АССР хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына сайлауларның йомгаклары турындагы мәсьәләне тикшерде.

Президиум хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар, массаның югары политик активлыгы белән үткәнлекне һәм Татарстан АССР хезмәт ияләренең ныклы мораль-политик бердәмлеген һәм Ленин—Сталин партиясе тирәсенә тупланганлыкларын тагын бер кат күрсәткәнлекне билгеләп үтте.

Татарстан АССР да тавыш бирергә хокуклары булган 1.441.570 сайлаучыдан җирле Советларга сайлауларда тавыш бирүдә 1.424.157 кеше катнашты. Бу—сайлаучыларның гомуми санының 98,8 проценты. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның гомуми санының 97,6 проценты коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатлары өчен тавыш бирде.

Барлык сайлау округлары буенча хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына 26.698 депутат сайланды. Шулар арасында партиясезләр 73,5 процент, хатын-кызлар 32,6 процент. Барлык сайланган депутатлар — коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары.

Сайлау кампаниясенә ун меңнәрчә хезмәт ияләре тартылды. Сайлау комиссияләре составында гына да 125.478 кеше катнашты. Шулар арасында партиясезләр—77,9 процент, хатын-кызлар—31,2 процент. Сайлаучылар арасында 60 меңнән артык агитатор, пропагандист һәм доверенныйлар эшләде.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы җирле Советлар алдына үзләренең эшләрен Сталин Конституциясе таләпләренә туры китереп иң кыска срок эчендә үзгәртеп кору бурычын куйды. Җирле Советларда төзелә торган даими комиссияләр—бюджет, сәүдә, мәктәп, җирле промышленность һәм башка комиссияләр үзләренең бөтен эшләрен депутатларның һәм хезмәт ияләренең киң массасының катнашуы нигезендә үзгәртеп корырга тиешләр.

Президиум җирле Советларның төп бурычларының берсе—Советларның актив практик эшенә барлык депутатларны тартудан—сайлаучылар алдында аларның җаваплылыкларын күтәрүдән гыйбарәт дип билгеләде.

⁂

Аннары Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы күп кенә пунктларны бер авыл советы карамагыннан икенчесе карамагына күчерү турында указлар кабул итте. Алексеевский районы, Балахчино авыл советындагы Шалбы авылы шул ук районның Солонцы авыл советы карамагына күчерелде. Солонцы авыл советының Ивановка авылы Алексеевский районының Сергеевский авыл советы карамагына күчерелде. Урта Тигәнәле авыл советының КызылОктябрь поселкасы Алексеевский районының Коры Көрнәле авыл советы карамагына күчерелде. Чигайка һәм Урицкий авыллары Кукмара районының Починок—Кучук авыл советыннан шул районның Кенәбаш авыл советы карамагына күчерелделәр.

(ТатТАСС).

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНЕҢ ХАТЛАРЫНА СИЗГЕР КАРАРГА

Хезмәт ияләре массасының матбугатта катнашы торган саен активлаша бара, хәбәрчеләрнең сафлары көннән-көн киңәя.

В. И. Ленин 1904 нче елны ук, матбугатны җанлы һәм тормышка якын итү өчен, газетага даими язып торучы биш җитәкче янына тагын әдәбиятчы булмаган биш йөз һәм биш мең работник катнаштырырга кирәклеген күрсәткән иде. Хәзер, совет демократиясе шартларында, партия тарафыннан кадрларны һәм барлык хезмәт иясе массаларын большевистик тәнкыйть һәм революцион уяулык рухында тәрбияләү бурычы бөтен үткенлеге белән куелган шартларда, Владимир Ильичның бу күрсәтмәсе аеруча әһәмиятле.

Хезмәт ияләренең газеталарга биргән хатлары тәнкыйтьне җәелдерүдә, хуҗалык һәм башка оешмаларның эшендәге бюрократик бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерүдә куәтле көч булып тора. Ләкин кайбер район партия оешмалары һәм аларның газеталары моңа тиешле бәя биреп җиткермиләр. Алар, шуның белән бергә, һәрбер хат артында җанлы кеше торганлыгын, социалистик төзелештә актив катнашучы торганлыгын, хезмәт ияләренең хатларына партия сизгер карашны таләп иткәнлеген онталар.

Хезмәт ияләренең хатларына, сигналларга игътибарсыз, бюрократларча карашларны кисәтеп, ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм Өлкә Комитетның берничә тапкыр күрсәтмәләре булды. Район оешмаларының җитәкчеләре хезмәт ияләренең хатларына сизгер карашны таләп итәсе урында, күбесенчә үзләре игътибарсызлык күрсәтәләр. Мәсәлән, Заинский район башкарма комитетына район газетасыннан җибәрелгән 13 хәбәр, район прокурорында 22, җир бүлегендә 50 хәбәр җавапсыз калдырылган. Милиция, райпотребсоюз һ. б. оешмаларда күп кенә сигналлар хәрәкәтсез ята. „Кызыл Зәй" газетасы редакциясе бу оешмаларның җитәкчеләренә карата чара күрүне ВКП(б) райкомыннан берничә тапкырлар сораса да, райкомның булышлык иткәне юк. Чөнки бу эштә Заинский райкомы (секретаре иптәш Иванов) үзе дә начар үрнәк күрсәтә: район газетасы тарафыннан узган ел монда җибәрелгән 27 хатның нәтиҗәләре турында да аларның авторларына хәбәр ителмәгән.

ВКП(б) ның Арча райкомы органы „Крепим колхозы" газетасы узган ел 59 номерда бары тик 177 хәбәр урнаштырган. Газетаның уннан тугыз өлеше рәсми материалларга яисә башка газеталардан күчереп алынган материалларга бирелгән. Узган 11 айга якын вакыт эчендә монда барлыгы 200 ләп кенә хат алынган булуы һәм газетаның тиражы да бик түбән булуы бары тик бу газетаның (редакторы иптәш Кирилловский) массадан ераклашкан булуы белән генә аңлатыла.

Шул ук районның татар телендә чыга торган „Яңа Тормыш" газетасы (редакторы иптәш Рамазанов) хатлар белән бер дә шөгылләнми дип әйтеп булмый, әлбәттә. Аның 70 тән артык хәбәрчесе бар, хәбәрчеләрдән меңнән артык хат алынган. Ләкин бу газетаның да зур кимчелекләре бар. Алынган хатларның өчтән бер өлеше (300 дән артык хат) файдаланылмыйча архивка ташланган. Тикшерү яисә чара күрү өчен төрле оешмаларга җибәрелгән 154 хатның 87 се буенча нәтиҗәләрен редакция белми. Мәсәлән, район җир бүлеге 20 хатка, райкомол 16 хатка җавап бирмәгәннәр. Ул гына да түгел, җир бүлегендә (мөдире иптәш Низаметтинов) редакциядән алынган 13 хатны бөтенләй югалтканнар. Район башкарма комитетында да хатларны югалту фактлары бар. Шунсы гаҗәп: хезмәт ияләренең хатларын җавапсыз калдыручыларга, хәтта югалтуларга чаклы барып җитүчеләргә карата бер нинди дә чара күрелгәне юк. Биләр, Ютазы районнарында да хәбәрчеләрнең хатлары белән эш шулай тора.

Бюрократларча бозуларны һәм һәр төрле җитешсезлекләрне бетерү өчен көрәштә большевистик тәнкыйть—партия кулында зур көчле корал. Шулай булгач, газета работниклары моңа гаять зур игътибар бирергә һәм хатлар аркылы хезмәт иясе массалары белән элемтәне нык җәелдерергә тиешләр. ВКП(б) ның Ютазы райкомы органы „Коммунизмга" газетасы бу мөһим бурычны үтәми генә түгел, хәтта газетада катнашырга омтылыш ясаучыларны да үзеннән ераклаштыра бара. „Соңга калды" һәм башка шундый „мотивлар" белән бу газета узган ел 300гә якын хәбәрне бөтенләй файдаланмыйча архивка ташлаган. Бу, редакциягә килгән барлык хәбәрләрнең 30 проценттан артыгы дигән сүз. Моңа, тикшерү өчен төрле оешмаларга җибәрелгән һәм нәтиҗәсез калган хәбәрләрне дә өстәсәк, газетада урнаштырылмаган хәбәрләр редакциягә килгән хатларның 60 процентын тәшкил итәләр.

Газетаның редакциягә килә торган һәрбер хатны басып чыгаруы мәҗбүри түгел, әлбәттә. Ләкин редактор алар арасыннан иң әһәмиятлеләрен сайлап алырга һәм бу хатлардан политик нәтиҗәләр чыгарырга, шушы хатларга нигезләп теге яисә бу мәсьәләне күтәрергә тиеш. Бу һәрбер газета работнигының беренче бурычы. Ә Ютазы район газетасының работниклары бөтенләй киресенчә эшлиләр. Менә түбәндәге мисалларне китерү генә дә җитә.

„8 нче Март" колхозы члены иптәш Гарифуллина үзенең 7 нче баласына 8 ай буена дәүләт пособиесе алуга ирешә алмагач, район газетасына мөрәҗәгать итә. Редактор иптәш Зиннәтуллин бу мәсьәлә белән шунда ук кызыксынасы урында, хатны өч атна буенча хәрәкәтсез яткыра. „Авангард" колхозында балалар яслесендәге җинаятле эшләр турындагы җидди сигнал редакциядә бөтенләй хәрәкәтсез калдырыла, хәбәрчегә дә җавап бирелми.

Авыл хуҗалыгы артеле уставын бозу, хуҗасызлык һәм хезмәт дисциплинасын бозулар турында редакциягә 116 хат килгән, шулардан бары тик 16 хат газетада файдаланылган. Оборона темасына язылган 30 хатның 15 нә газета урын „тапмаган". Аларның күбесе кызыл армеец хатлары. Шулай ук социалистик ярыш, стахановчылык хәрәкәте турында язылган 88 хаттан 50 се архивка ташланган. Аларның гаять күпчелеге бюрократик резолюцияләр белән чуарланганнар. Мәсәлән, ВКП(б) ның XVIII нче съездын каршы алу уңае белән, Кызыл Яр авылындагы тулы булмаган урта мәктәп укытучылары йөкләмә алып, районның барлык укытучыларын социалистик ярышка чакыралар. Архивка ташланган бу хатка бюрократларча шушындый резолюция салынган: „Киләчәктә йөкләмәне үтәгәннән соң язарга булыр. Эшне эшләми торып, кәгаздә язылганнар буенча гына газетага кертеп булмый".

Мондый мисалларне бик күп китерергә була. „Коммунизмга" газетасы тикшерү яисә чара күрү өчен җибәргән хатларның нәтиҗәлелекләре өчен дә көрәшми. Редакциядән төрле оешмаларга 182 хәбәр җибәрелгән, шулардан 113 хәбәргә җавап алынмаган, авторларына да хәбәр ителмәгән.

Арча район газетасының ел буена бары тик 200 хат алуы, ай саен 150—160 хат алып килгән Ютазы район газетасының соңгы вакытта айга 40—60 кына хат ала башлавы, югарыда әйтеп үткәнчә, хезмәт ияләренең хатларына игътибарсыз, бюрократларча караудан килеп чыкканнар. Бу, һич түзеп торырлык хәл түгел.

Хезмәт ияләренең хатларына, сигналларга тиешлечә бәя биреп җиткермәү фактлары кайбер прокуратура органнарына да кагыла. СССР прокуратурасының директивалары буенча, прокуратура органнары газеталардагы заметкаларда һәм иглан ителмәгән хатларда язылган фактларны 10 көннән дә соңга калмыйча тикшерергә, газета редакцияләренә җавапны вактында бирүгә контроль булдырырга тиешләр. Ютазы, Заинский һ. б. район прокурорлары контроль булдыру урнына, туп-туры үзләренә җибәрелгән сигналлар буенча да чара күрмиләр, еш кына аларны хәрәкәтсез калдыралар.

Хезмәт ияләренең хатларына, газета сигналларына җансыз, бюрократларча караш бик тизлек белән бетерелергә тиеш.

⁂

Совет кешесе турында кайгырту партия тарафыннан иң югары дәрәҗәгә күтәрелде. Бу, газета редакцияләренә килгән хатларга игътибарны һәм сизгерлекне гаять дәрәҗәдә югары күтәрүне таләп итә. Чөнки, кабатлап әйтергә кирәк, һәрбер хат артында социалистик төзелешкә актив катнашучы җанлы кеше тора.

Әһәмияте булган һәрбер хатның газетага керүе, ул хатны язучыны җәмагат-политик эшкә тарту икәнлекне һәрбер газета работнигы ачык аңларга тиеш. Газетада басылган һәрбер хат, аны язучы кеше өчен зур бер вакыйга. Хатка тиешле игътибарны бирмәү зур җинаять.

Иптәш Сталин ВКП(б) Үзәк Комитетының февраль - март пленумында масса белән элемтә мәсьәләсенең әһәмияте турында болай диде: „Массалар белән элемтә, бу элемтәне ныгыту, массалар тавышына колак салырга һәр вакыт хәзер тору,—большевистик җитәкчелекнең көче һәм җиңелмәслеге менә шунда".

Юлбашчыбызның бу күрсәтмәсен һәр вакыт истә тотарга һәм аны тормышка ашыру өчен нык көрәшергә кирәк.

Һәрбер хатка мәхәббәт белән карау, бер хатны да җавапсыз калдырмау, нәтиҗәлелек өчен көрәш, ниһаять, массалар белән элемтәне көннән-көн ныгыту—газета работникларының сугышчан бурычы.

Н. Мәҗитев.

АВЫЛ СОВЕТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШЛАРЫ

ЧИСТАЙ РАЙОНЫНДА

Чистай районы Кубас авыл советының беренче утырышы булды. Утырышка колхозның алдынгы кешеләре—„Доброволец“ колхозы члены 67 яшьлек Герман Васильевич Максимов, колхоз фермасының көтүчесе иптәш Штурмин, армиядән кайткан иптәш Спирин, „Кама“ колхозы стахановчылары Шмагина, Егорова һәм башка иптәшләр кунак итеп чакырылдылар.

Утырышны авыл советының карт депутаты, „Доброволец“ колхозының парторгы Анна Тимофеевна Галактеева ачты. Ул депутатларны коммунистлар һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының гүзәл җиңүе белән котлады. Элек—патша Россиясендә хатын-кызларның хокуксыз яшәгәнлекләренә, ул авыр, лагнәтләнгән тормышның хәзер мәңгегә бетерелгәнлегенә тукталып, болай диде:

— Элекке вакытта хәерчелектә һәм ярлылыкта яшәгән безнең Кубас авылында хәзер үзенең терлекчелек фермалары, машиналашкан эре хуҗалыгы һәм һәр төрле мастерскойлары булган „Доброволец“ колхозы үсә һәм чәчәк ата. Һәрбер колхоз члены таза һәм иркен тормышта яши. Безнең хатын-кызлар ирләр белән бер тигез булып производствода эшлиләр, дәүләт белән идарә итәләр.

Утырыш, авыл советы башкарма комитетының председателе итеп иптәш Петрянинны, аның урынбасары итеп иптәш Шкуровны, секретаре итеп „Кама“ колхозы члены иптәш Новиковны сайлады.

Утырыш авыл советының башкарма комитетын сайлады һәм даими 4 комиссиясен раслады. Сәламәтлек саклау комиссиясенең җитәкчесе итеп депутат Василий Григорьевич Горюнов, авыл хуҗалыгы комиссиясе җитәкчесе итеп „Кама“ колхозының бригадиры—депутат Федор Степанович Шкуров расландылар.

ШӨГЕР РАЙОНЫНДА

ШӨГЕР. (Телефон буенча). Каратай авыл советының беренче утырышын авыл советының иң карт депутаты—колхозчы иптәш Шәрәпов ачты.

Утырыш Вәлиахметова Фахирә (орденлы укытучы), Шәрәпов Нурытдин һәм Галәветтинов Шәйхелислам иптәшләр составында мандат комиссиясе сайлады. Аннан соң авыл советының башкарма комитеты председателе итеп Якупов, аның урынбасары итеп Ильясов һәм секретаре итеп Сәмикова иптәшләр сайланды. Утырыш мандат комиссиясенең докладын тыңлаганнан соң, авыл советына барлык депутатлар ТАССР Конституциясенә һәм җирле Советларга сайлаулар турындагы положениегә тулысынча туры китерелеп сайланганнар дип тапты. Утырыш даими комиссияләр сайлады.

Үзбеков.

ПИТРӘЧ РАЙОНЫНДА

Шәле авыл советының беренче утырышы булды.

Депутат иптәш Мәҗитова утырышны ачу эшен иң карт депутат Хәмидулла бабай Маннаповка тапшырырга тәкъдим итте. Бу тәкъдим алкышлап каршы алынды. Кыскача кереш сүз сөйләп, Хәмидулла бабай утырышны ачык дип белдерде.

Утырыш мандат комиссиясе, авыл советының башкарма комитетын сайлады. Авыл советы башкарма комитетының председателе итеп, авыл советында 9 ел буенча председатель булып эшләүче иптәш Вәлиуллин, секретаре итеп Миңлебаева иптәш сайланды.

Даими комиссияләрдән бюджет, сәламәтлек саклау һәм терлекчелек комиссияләре төзелде.

Х. Гарипов.

ЮДИНО РАЙОНЫНДА

Юдино районының Зур Коргызә, Айша, Зур Ключ һәм башка авыл советларының беренче утырышлары булып үтте. Халык тарафыннан сайланучылар үзләренең эшләрен үтәүгә керештеләр. Зур Коргызә авыл советының беренче утырышын иң карт депутат иптәш Газиз Мөхәммәтҗанов ачты. Ул 10 ел буена өзлексез рәвештә шул авыл советының члены булып эшли. Үзенең чыгышында иптәш Мөхәммәтҗанов гаять зур шатлык белән, Сталин Конституциясе кояшы астында хезмәт ияләренең бәхетле, культуралы, иркен тормышта яшәүләре турында сөйли:

— Хәзер безнең авылда культура көннән-көн чәчәк ата, — ди ул. Бездә башлангыч һәм урта мәктәп, клуб бар. Соңгы елларда безнең авылдан 8 укытучы, 14 тракторчы чыкты.

— Халык авыл советына депутат итеп сайлап, безгә зур ышаныч күрсәтте. Бу ышанычны без намус белән һәм большевистик эш белән акларга тиешбез, — ди иптәш Мөхәммәтҗанов.

Утырыш, 5 депутат составында, авыл советы башкарма комитеты сайлады. Авыл советы башкарма комитетының председателе итеп авыл советының элеккеге председателе иптәш Хәкимуллин сайланды. (ТатТАСС).

САБА РАЙОНЫНДА

Кильдебәк авылы советының беренче утырышын, зур алкышлар астында, карт депутат иптәш Гыйлаҗеттинев ачты.

Авыл советының беренче утырышы түбәндәге мәсьәләләрне карады:

Мандат комиссиясе сайланды һәм мандат комиссиясенең председателе иптәш Арыслановның доклады тыңланды.

Шуннан соң авыл советының башкарма комитетын сайлау мәсьәләсенә күчелде. Башкарма комитетының председателе итеп иптәш Гарипов, аның урынбасары итеп иптәш Гыйсмәтуллин, секретаре итеп иптәш Абдуллин һәм 5 член сайланды.

Соңгы мәсьәлә булып даими 4 комиссия төзелде, аларның җитәкчеләре расланды.

Х. Исламов.

БУА РАЙОНЫНДА ЧӘЧҮГӘ НАЧАР ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Буа районының күпчелек колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек эшләре әле дә булса башланмаган диярлек. Мәсәлән, „Стадие“ колхозында (председателе иптәш Фәхретдинев) язгы чәчү өчен 3 мең центнердан артык орлык кирәк. Ләкин моның әле 1.100 центнеры гына хәзерләнгән. 250 генә центнер орлык чистартылган. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эше дә начар тора. 70 сабан, 86 тырма, 11 сеялка ремонтланмаган. Ләкин колхоз җитәкчеләренең моңа бер дә исләре китми. Җирле ашламалар хәзерләү турында уйлап та караучы юк.

„Идеял“ һәм Ленин исемендәге колхозларда чәчүгә хәзерлек тагын да начарырак тора. Бу колхозларда орлык чистарту, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарына ремонт ясау башланмаган да. Ленин исемендәге колхоз председателе Зиаттинев чәчүгә хәзерлек эше белән шөгыльләнми. Ул системалы рәвештә диярлек эчү белән шөгыльләнә. Куйбышев, Молотов исемендәге колхозларда һәм „Ответ интервентам“, „Красная Армия“, „Память Ленина“ колхозларында да язгы чәчүгә хәзерлек эше мактарлык түгел.

Район буенча орлык хәзерләү планы 84 процент, чистарту 40 процент, орлыкларга анализ ясау 29 процент кына үтәлгән.

Тракторларга ремонт ясау аеруча начар тора. Буа МТМы Татнаркомзем планы буенча, Буа һәм Әхмәмәт МТС ларының 98 тракторына ремонт ясарга тиеш. Шулардан 1939 нчы елның октябрендә 13, ноябрь һәм декабрь айларында 30 тракторга ремонт ясалырга тиеш иде. Ләкин октябрь аенда бер трактор да ремонттан чыкмады. Ноябрь һәм декабрь ае планы да 65 процент кына үтәлде. Бу хәл, барыннан да элек, МТМ ның ремонт сезонын хәзерлексез каршылавы һәм МТМ җитәкчеләренең ремонтка тиешле җитәкчелекне тәэмин итмәүләре белән аңлатыла. Ремонтчылар кадрларын туплау әле һаман төгәлләнмәгән. Ноябрь аенда вкладышлар коючы булмаганлыктан 5 трактор моторы ремонттан чыгарылмады. Җыю цехында да эшчеләр җитешми. Шуның нәтиҗәсендә, ремонтланып беткән моторларның берничә көннәр җыелмый тору фактлары бар.

Договор нигезендә Буа һәм Әхмәмәт МТС лары ремонтта эшләү өчен МТМ га алтышар кеше беркетергә тиешләр иде. Буа МТС ы бу кешеләрне декабрь аенда гына җибәрде. Ә Әхмәмәт МТС ыннан тиешле кешеләр хәзергә кадәр килеп җитмәгән.

МТМ ның алдынгы эшчеләре ремонт буенча даими бригадалар төзү турында тәкъдим биргәннәр. Ләкин МТМ (директоры иптәш Абылханов) һәм МТС җитәкчеләре бу тәкъдимне „файдасыз“ дип кире какканнар. Даими бригада булмаганлыктан һәм МТС лардан килгән эшчеләрнең составы һәр көн диярлек алмашынып торганлыктан, иясезлеккә юл куела. Эшчеләр көн саен яңа эшкә күчереләләр.

МТМ җитәкчеләре социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтен җәелдерү өчен тиешле чараларны күрмиләр. Аңлату эшләре йомшак куелган. Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу өчен производство киңәшмәләре үткәрелми. Стена газетасы бөтенләй чыгарылмый. Мастерскойда эшләү өчен уңайлы шартлар тудырылмаган. Эшчеләр, яктылык булмау сәбәпле, 8 сәгать урынына 6 гына сәгать эшлиләр.

Бу җитешсезлекләр тиз арада бетерелмәсә, Буа районының язгы чәчүне начар хәзерлек белән каршылау куркынычы бар.

Район оешмалары моны нык искә алырга һәм язгы чәчүгә хәзерлек эшенә тиешле җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр.

С. Вахитов.

БЕР УРЫНДА ТАПТАНЫП ТОРУНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Буденный МТС ында 57 тракторга, 35 сеялкага, 28 культиваторга һәм 67 сабанга ремонт ясалырга тиеш. Ремонт эшләре сентябрьнең икенче яртысында ук башланган иде. Димәк, ремонт эшләре башлануга 3 айдан артык вакыт үткән дигән сүз. Ләкин ремонттан бары 12 генә трактор чыккан. Аларның да сыйфаты нинди булуы турында дирекция ачык әйтә алмый. Чөнки ремонттан чыккан тракторлар комиссия тарафыннан кабул итеп алынмаган.

Буденный МТС ында ремонт эшләренең шулай акырын баруының сәбәбен дирекциянең бу эшкә оператив җитәкчелек итмәвеннән эзләргә кирәк. Ремонтчылар арасында хезмәт дисциплинасын бозу киң урын алган. Менә берничә факт. Тимерче Шубин бер кемнең рөхсәтеннән башка авылына китеп 10 көн эшкә килми тора. Шушы вакыт эчендә мастерскойда бөтен эш туктала. Ә дирекция бу турыда бөтенләй белми. 5 нче бригада бригадиры Юсупов, 10 нчы бригада бригадиры Бохариев һәм аның ярдәмчесе Сирюков, тракторчылардан Кыям Юсупов һәм Фәсхи Хәйсаров һәрберсе 3—5 көн прогул ясаганнар. Бу кешеләр эшкә килгән көннәрдә дә икешәр сәгать кичегеп киләләр. Дирекция аларга карата бер чара да күрми, хезмәт дисциплинасы турындагы законны тупас рәвештә боза.

Ремонт эшендә тәҗрибәсе зур булган алдынгылар бар. 12 нче номерлы трактор отряды бригадиры иптәш Лотфуллин һәм аның бригадасында эшләүче тракторчылардан Сабир Гарифуллин, Гилметтин Алиуллов һәм Таһир Лотфуллин иптәшләр ремонт эшендә бик күпләргә үрнәк булып торалар. Бу бригада үзенә беркетелгән тракторларга ремонт ясауны төгәлләде. Бригада ремонт эшендә барлык мөмкинлекләрдән файдалануны оештырды. Җитешмәгән частьләрне табып китергәнне көтеп тормыйча, төзәтергә яраклы иске частьләрне яңартты. Ләкин МТС ның директоры Аширов һәм политик эшләр буенча директор урынбасары Максудов иптәшләр алдынгыларның үрнәкле тәҗрибәләрен башкаларга күчерү буенча кыл да кыймылдатмыйлар.

Эшчеләр арасында социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек бик йомшак. Моннан бер ай элек бригадалар арасында ярыш договорлары төзелгән булса да, ул эшчеләр катнашы белән өйрәнелмәгән һәм аның үтәлеше тикшерелмәгән. Шуңа күрә МТС җитәкчеләренең алдынгы кешеләрне, стахановчыларны белмәүләре очраклы түгел.

Татарстан МТС ларында һәм МТМ нарында тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда социалистик ярыш оештыру турында ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Совнаркомы карары МТС коллективында өйрәнелмәгән.

Буденный МТС ының тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясауда һаман бер урында таптануының төп сәбәпләре әнә шулар. Шушылардан соң МТС җитәкчеләренең „частьләр юк, теге җитешми, бу җитешми“ дигән сылтаулар белән акланырга тырышуларының никадәр урынсыз булуын аңлавы читен түгел.

А. Яфизов.

Алексеевский райкомолы язгы чәчүгә хәзерлек турында башлангыч оешмаларның секретарьлары белән өч көнлек семинар үткәрде. РӘСЕМДӘ: агроном иптәш А. И. Сахарова лекция укый.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЕЛЛЫК ПЛАН ҮТӘЛДЕ

Мөслим районы, Яңа Агбәс авыл советы финанс туплау планын үтәүдә бик яхшы күрсәткечләр бирә. Авыл советы 1939 нчы елда финанс туплау буенча беренче квартал планын 104 процент, II нче квартал планын 194 процент, III нче квартал планын 155 процент, IV нче квартал планын 139 процент итеп үтәде.

Ирекле түләүләр зур уңышлык белән җыелып бетте. Өченче бишьеллык (икенче ел чыгарылышы) заемы облигацияләре буенча взнослар җыю эше 1939 нчы елның 1 нче октябренә 105 процент итеп үтәлде. Хөсәенев, Хөснуллина һәм Галимов иптәшләр заем взносларын җыюда аеруча тырышып эшләделәр.

Авыл Советы бу уңышларга финанс секциясе һәм комсодның актив белән бергәләп эшләүләре һәм эшне план буенча алып барулары нәтиҗәсендә иреште.

Агбәс авыл советы финанс эшчеләренең слетында район финанс бүлеге һәм финанс-банк работниклары союзының район комитеты тарафыннан күчмә кызыл байрак һәм патефон белән бүләкләнде.

М. Юнусов.

Алдынгылык өчен көрәшәләр

Арча районында ирекле страхование буенча 1939 нчы ел планы 10 нчы декабрьгә 27 мең сум урнына 37 мең 635 сум итеп үтәлде.

Кайбер авыл советларындагы страховой инспекторлар һәм налог агентлары бу эштә аеруча активлык күрсәттеләр. Мәсәлән, Күпербаш авыл советының налог агенты иптәш Гимадиева, Мөндеш авыл советында иптәш Сабиров ирекле страхование планын 510—550 процентка кадәр җиткереп үтәделәр.

Районның Иске Чүриле, Арча, Наласа авыл советларында ирекле страхование планы 233—396 процент итеп үтәлде.

Н. Хайруллин.

Айлык план арттырып үтәлде

3 нче фанер заводының утиль цехы айлык планны 12 нче декабрьдә арттырып үтәде. Цех шул вакыт эчендә 56 мең сумлык киң куллану товарлары эшләп чыгарды.

Фанера кисү станокларында эшләүчеләрдән Развалова, Иватина, Панина, Юдина, Детентиева һәм Стрелкова иптәшләр үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә көнлек нормаларын 130 — 150 процент итеп үтәүгә ирештеләр.

Балта осталарыннан Ефимов, Малугин, Зинин, Иваницкий, Мүллин һәм Карпов иптәшләр көнлек заданиеләрен 180—250 процентка кадәр җиткереп үтиләр. Бу иптәшләр эшләгән мебельләрнең сыйфаты яхшы.

И. Фәйзуллин.

БАЛТАЧ. (Телефон буенча). Кожпромсоюз системасындагы „Стахановчы“ (Балтач авылы) һәм „Кызыл мехчы“ артельләре җирле Советларга сайлауларга кадәр декабрь планын үтәргә йөкләмә алганнар иде. Производство активлыгының нык үсүе һәм социалистик ярышны җәелдерү нәтиҗәсендә, артельләр үзләренең йөкләмәләрен срогыннан элек үтәүгә ирештеләр. „Стахановчы“ артеле 20 нче декабрьгә айлык планны 130 процент итеп үтәде. Артельнең стахановчыларыннан иптәш Бикбаева, Шәймуллина, Фәхриева һәм башка иптәшләр көнлек нормаларны 180—200 процент итеп үтәп баралар.

Арбаш авылындагы „Кызыл мехчы“ артеле декабрь планын 11 нче декабрьдә үк үтәде. Мехлар кисү цехы стахановчысы Гыйбадуллина, Шәрәфеттинова иптәшләр норманы 170—190 процент итеп үтиләр. Сайлау алды ярышында артельдә стахановчылар саны 45 кешегә артты.

Р. Тимерев.

УҢЫШЛЫ ЕЛНЫҢ ҖИМЕШЛӘРЕ

Советлар Союзы халыклары яңа елны — 1940 нчы елны зур күтәренкелек һәм шатлык белән каршы алды. Бу, табигый. Чөнки безнең илебездә һәрбер эшче, һәрбер колхозчы, һәрбер интеллигент бүген матур булган тормышының иртәгә тагын да күңеллерәк, тагын да гүзәлрәк булачагын яхшы белә.

Һәр яңа ел безнең илебез халыкларына социалистик төзелештә яңа җиңүләр китерә, һәр яңа ел безне кешелек җәмгыятенең идеялы булган коммунизмга якынайта.

Совет иле шартларында миллионлаган хезмәт ияләре үзләренең теләкләрен тулысынча тормышка ашыра алалар. Чөнки безнең илебездә һәр кем үзенең тормышына хуҗа, һәр кемгә тормышка киң юл ачык. Узган 1939 нчы ел һәрбер совет гражданына үзенең гүзәл эзен һәм матур истәлеген калдырды. 1940 нчы ел киң тормыш перспективасын ача.

Сүзне Серго Орджоникидзе исемендәге заводның кешеләренә бирик. Менә Виктор иптәш **Гансаревич**.

Узган 1939 нчы ел аның тормышында аеруча зур вакыйгаларгә бай булган тарихи ел булып хисаплана. Хасан күле районындагы сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен СССР Верховный Советы иптәш Гансаревичны „Кызыл Байрак“ ордены белән бүләкләде. 24 нче декабрьдә иптәш Гансаревичка сайлаучылар тарафыннан гаять зур ышаныч күрсәтелә — ул хезмәт ияләре депутатларының район советына депутат итеп сайланды.

— Бу бәхетле көннәрне мин бер вакытта да онытмам, ди Виктор Гансаревич. Бу зур вакыйгаләр иптәш Гансаревичка тагын да зуррак теләкләрне кузгата. Ул 1940 нчы елда Сталин исемендәге Промакадемиягә укырга керергә хәзерләнә.

Узган 1939 нчы ел мастер иптәш **Смирнов** семьясенә аеруча зур шатлык китерде. Иптәш Смирнов Казан Шәһәр Советына, аның тормыш иптәше Мария Алексеевна район Советына депутат итеп сайландылар. Алар бу мактаулы хезмәтне зур шатлык белән кабул иттеләр. Иптәш Смирнов үзенең производство квалификациясен күтәрү теләге белән 1940 нчы елда тугандаш заводларга фәнни командировкага баруны күздә тота.

Цех начальнигы иптәш Закутаев: „1939 нчы елда минем тормышым гаять әһәмиятле вакыйгаләргә очрады. Узган ел мин коммунистлар партиясе сафына кабул ителдем. Район советына депутат итеп сайландым. Производствоны рационаллаштыру буенча күп кенә тәкъдимнәр биреп, заводка 200 мең сумнан артыграк экономия ясауга ярдәм иттем. Яңа, яхшы квартирага күчтем. 1940 нчы елны үземнең политик белемемне күтәрү өстендә тагын да тырышып эшләячәкмен. Хәзер мин елына 250 мең сум экономия ясарлык рационализаторлык тәкъдимнәре бирү өчен хәзерлек эшләре алып барам“ ди.

Район Советы депутаты инженер иптәш **Артемьев** узган ел да күп кенә фәнни хезмәтләр өстендә эшләде. Инглиз телендә язылган байтак кына техника китапларын рус теленә тәрҗемә итте. Иптәш Артемьев 1940 нчы елда техника фәне кандидатлыгына гыйлми дәрәҗә алу өчен диссертация якларга хәзерләнә.

Совет кешеләренең җәмгыяттә тоткан дәрәҗәләре елдан-ел күтәрелә. Шул ук вакытта аларның культура, тормыш - көнкүреш шартлары да көннән көн яхшыра бара. Менә иптәш **Чупатов**. Ул, үзенең техника белемен күтәрү өстендә тырышып эшләве һәм производствода зур хезмәтләр күрсәтүе аркасында мастерлыктан цех прораб ярдәмчесе постына күтәрелде. Иптәш Чупатов бу эштә дә тырышып эшли, производство программасын һәр айда арттырып үти. Күптән түгел аның группасына цехның күчмә кызыл байрагы тапшырылды. 1940 нчы елда иптәш Чупатов үз участкысында эшне тагын да яхшырак итеп оештыруны һәм кызыл байракны саклап калуны үзенә төп бурыч итеп куйды.

Район Советы депутаты инженер Зариф **Асадуллин** 1939 нчы елда яшь эшчеләрдән 17 кешене катлаулы станокларда эшләргә өйрәтеп чыгарды. Алар дәүләт экзаменын яхшы һәм отлично билгеләренә тапшырдылар. Бу иптәшләр хәзер барсы да стахановчылар, производство заданиесен 180—300 процентка кадәр үтәп, югары сыйфат күрсәткечләре бирәләр. Иптәш Асадуллин 1940 нчы елда тагын да зуррак хезмәтләр башкарырга хәзерләнә. Ул, автомат станокларда наладчик булып эшләүчеләр өчен техминимум буенча китап язарга хәзерләнә. Иптәш Асадуллин 1940 нчы елда үзенең җәйге ялын Кавказ яки Кырымда уздырырга уйлый.

Безнең илдә хезмәт мактау һәм дан эше. Илебез һәрбер яңа елны производствола гаять зур җиңүләргә ирешү белән каршылый. Стахановчылык хәрәкәте эшнең һәр тармагында үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Заводның стахановчы слесаре Искәндәрев Мотыйк 1939 нчы елда үзенең производство планын 200—250 процент итеп үтәп килде. Югары сыйфатлы продукция эшләп чыгарды. Иптәш Искәндәрев 1940 нчы елда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча тагын да югарырак күрсәткечләр бирергә ышаныч белдерә.

Заводның алдынгысы Вәли иптәш Сабиров заводка түбән квалификацияле эшче булып килде. Ул шушы еллар эчендә үзенең техника белемен күтәрүне үз алдына төп бурыч итеп куйды һәм үз өстендә бик нык эшләде. Нәтиҗәдә, иптәш Сабиров 1939 нчы елда, производстводан аерылмыйча, завод каршындагы социалистик хезмәт мастерлары мәктәбенең II нче курсын уңышлы рәвештә тәмамлады. Барлык фәннәр буенча отлично билгеләре алды. Иптәш Сабировның тырышып укуы бушка китмәде. Аны слесарьлыктан технолог итеп күтәрделәр. Быел иптәш Сабиров мастерлар мәктәбенең соңгы курсын отлично билгесенә тәмамлап, югары уку йортына керергә хәзерләнә.

Узган ел эчендә тормышларында әһәмиятле, шатлыклы вакыйгаләр булган һәм яңа елны киң планнар, матур теләкләр белән каршы алучылар безнең заводта бик күп. Менә технолог Варварин. Аны заводта белмәгән кеше юк. Ул техникумда укыган вактында ук физкультура-спорт эше белән нык шөгыльләнә иде. 1939 нчы елны ул авырлык күтәрү буенча беренче разряд норма тапшырды. Штанг спорты буенча Татарстан күләмендә өч рекорд бирде. Иптәш Варварин 1940 нчы елда штанг спорты буенча мастерлык исмен алуны үзенә бурыч итеп куя.

Цех мастеры, яшь альпинист иптәш Митушкинга узган ел зур яңалык китерде. Ул норма тапшырып, СССР ның беренче дәрәҗә альпинисты значегын алуга иреште. Иптәш Митушкин киләсе җәйдә тагын Кавказ тауларына барып СССР ның икенче дәрәҗә альпинисты значегын алырга хәзерләнә. Иптәш Митушкинның икенче бер зур теләге—ВКП(б) сафына керү. Моңа ирешү өчен иптәш Митушкин үзенең идея-политик дәрәҗәсен күтәрү өстендә нык эшли, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнә.

1939 нчы ел үтте. Ул тарихка зур бәхет һәм җиңү елы булып керде. 1940 нчы ел илебез һәм аның халыклары өчен тагын да матуррак һәм шатлыклырак булачак. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның җитәкчелеге астында коммунизмга баруда тагын да зуррак адым ясаячак. Әнә шуңа күрә дә Серго Орджоникидзе исемендәге заводның хезмәт ияләре, илебезнең барлык халыклары белән бергә, яңа елны зур шатлык белән каршыладылар һәм үзләренең киләчәкләре өчен яңа җиңүләргә зур планнар төзеделәр.

С. Кәримуллин.
Г. Рәфик.

АЛДЫНГЫ АРТЕЛЬ

Биләр районының „Верный Путь“ артеле членнары хезмәт ияләренең җирле органнарына сайлаулар көнен производствода гүзәл җиңүләргә ирешү белән каршыладылар. Артель еллык планны 24 нче декабрьгә 138 процент итеп үтәде. Шуның белән бергә эшләнгән продукциянең үзенә төшкән бәясен дә 18 процентка кадәр киметүгә иреште.

Артельнең аерым стахановчыларыннан Добранравов һәм Штанников иптәшләр айлык планны һәр вакыт 125—250 процентка җиткереп үтиләр.

Ф. Кыямов.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 1 гыйнвар. (ТАСС). Кичә кич белән иглан ителгән белдерүдә, көн тыныч үтте, диелә.

Бүген иртә белән иглан ителгән рәсми белдерүдә, фронтның барлык линияләрендә дә артык бер нәрсә дә булмады, диелә.

БЕРЛИН, 1 гыйнвар. (ТАСС). Германия верховный командованиесе бүген түбәндәге сводканы тапшыра: „Көнбатыш фронтта артык бер нәрсә дә булмады. Кичә дошманның самолетлары Германия ярларына якын килергә маташтылар, ләкин шул вакытта ук сизелделәр һәм Германиянең һава һөҗүменә каршы көчләре тарафыннан куып җибәрелделәр“.

Төркиядә җир тетрәү уңаե белән Совет хөкүметенең Төркия хөкүмәте кайгысын уртаклашуы

ӘНКАРӘ, 1 гыйнвар. (ТАСС). СССР ның Төркиядәге илчесе иптәш Терентьев бүген чит ил эшләре министре Сараҗогло янында булды һәм Төркиянең көнчыгыш районнарында булган һәлакәт уңае белән, Совет хөкүмәте исменнән Төркия хөкүмәтенә кайгы уртаклашуын белдерде.

ТӨРКИЯДӘ ҖИР ТЕТРӘҮНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

ӘНКАРӘ, 1 гыйнвар. (ТАСС). Төркия хөкүмәте һәлакәтнең күләмнәре турында бары тик бер тәүлек үткәннән соң гына белде, чөнки җир тетрәү булган районнар белән һәр төрле элемтә өзелгән иде. Беренче мәгълүматларга караганда, җир тетрәү вактында берничә ун меңнәрчә кешеләр һәлак булган. Бу саннарның бары тик шәһәрләрдә торучы халыкка карата гына булганлыгын да әйтергә кирәк. Авылларда нәрсәләр булуын бер кеше дә белми. Авыл халкы арасында һәлак булучылар саны шәһәрдәгеләрдән ким түгелдер, дип хисаплыйлар. Җир тетрәү булган районнарда хәлнең авырлыгы шуннан гыйбарәт ки, исән калган кешеләр юл булмаганлыктан, ярдәм ала алмыйлар. Үзәк районнардан бүленеп калган авыллардагы халыкның хәле бигрәк тә авыр. Һәлакәткә очраган халыкны азык әйберләре белән тәэмин итү чиктән тыш кыенлашкан. Җир тетрәү булган районнардагы халыклар суыктан һәм ачлыктан үләләр.

Төркия хөкүмәте самолетлар ярдәме белән халыкны җылы кием һәм башка төрле кирәкле предметлар белән тәэмин итүне оештырырга уйлый. Бөтен илдә һәлакәткә очраучылар файдасына ярдәм җыю дәвам итә.

Совет—Литва мөнәсәбәтләре турында Литва газетасы

КАУНАС, 1 гыйнвар. (ТАСС). „XX амжиус“ газетасы яңа ел номерында болай дип яза: „1940 нчы елны безнең яшь дәүләтебез шактый үзгәргән обстановкада каршы ала. Польша югалды. Советлар Союзы Литваның турыдан-туры күршесе булып әверелде. Үзара ярдәмләшү турында Совет—Литва пакты безнең киләчәгебез өчен гадәттән тыш әһәмиятле булачак. Без беләбез, СССР белән безнең мөнәсәбәтебез тату күршеләрчә булып калыр. Яңа елда бу мөнәсәбәт нәчарланыр дип борчылырга, безнең бер нинди нигезебез юк. Безнең юлыбыз элеккечә кала—тынычлык, хокук һәм гаделлек“.

Швециядә коммунистик газета редакторына суд процессы

СТОКГОЛЬМ, 1 гыйнвар. (ТАСС). Шушы көннәрдә генә Стокгольмдә Швециядә чыга торган „Ню даг“ дигән коммунистик газета редакторы Лагерга суд булды. Лагер, Финляндия коммунистлар партиясенең мөраҗәгатен басып чыгарган өчен суд җаваплылыгына тартылган иде. Суд Лагерны ике айга төрмәгә ябарга хөкем итте.

Полициянең тыюына да карамастан „Юманите“ газетасы чыга

ЛОНДОН, 1 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасы, Франция компартиясе тыелган „Юманите“ газетасын чыгаруны дәвам иттерә, дип белдерә. Бер Париж районында гына да газета һәр көнне 20 мең данә тарала. „Юманите“ газетасын һәр көнне уртача 100 меңнән алып 150 меңгә якын эшче укый. Рено заводларында газетаның һәрбер данәсен 50 дән артык эшче укый. „Шулай итеп,—ди „Дейли Уоркер“,—профсоюзларның барлык революцион членнары өчен газета берләштерү үзәге булып тора“.

Яңа ел бәйрәме кичәләреннән. РӘСЕМДӘ: сулда—„Спартак“ клубында. Унда—Казан Тимер юлы идарәсе йортында бал-маскарад.

М. Солтанов, И. Галиев фотосы.

АЛДЫНГЫ МӘКТӘПТӘ

Кукмара районының беренче номерлы урта мәктәбе районда иң алдынгы мәктәпләрдән санала. Мәктәптә политик-тәрбия эшләрен яхшы итеп оештыруда комсомол, пионер оешмалары зур урын тоталар. Биредә, уку елы башланганда 14 комсомолец, 25 пионер бар иде. Хәзер комсомолецларның саны 40 ка җитте. Мәктәптә Осоавиахим, Сугышчан Алласызлар Союзы, РОКК, МОПР оешмалары бар. ПВХО, ГСО, Ворошиловча атучылар, ГТО значекларына нормалар тапшыру оештырылды, драма һәм башка түгәрәкләр эшлиләр. Ирекле оешмаларның һәм түгәрәкләрнең эшләренә комсомолецлар һәм пионерлар үзләре җитәкчелек итәләр.

Комсомолец иптәш Сабатиев җитәкчелек итә торган ПВХО түгәрәге аеруча яхшы эшли. Уку елы башланганнан соң түгәрәкнең 6 занятиесе булды. Түгәрәктә, газлар һәм алардан саклану чаралары турында беседалар үткәрелде. Биредә күргәзмә материаллардан күп файдаланыла.

Драма түгәрәге көче белән Зур Кукмара авылында, мәктәптә һәм Кукмара поселкысы клубында концерт, спектакльләр куела.

Мәктәптә 10 исемдә стена газеталары чыгарыла. Редколлегия членнары газеталарны тирән эчтәлекле итеп үз вактында, художество ягыннан матур итеп чыгаруга зур игтибар бирәләр.

Мәктәптә 75 пионер бар. 4 нче „А“ һәм 4 нче „Б“ классларында (укытучылары Кадыйрова һәм Шиһапова иптәшләр) укучыларның бары да пионерлар. Пионерларның күпчелеге „отлично“ һәм „яхшы“ билгеләренә генә укыйлар. Комсомолецлардан Фазлиев, Баширова, Маякова, Усманов; пионерлардан Кәшипова, Гыйматова, Шакировалар уку елының беренче чиреген „отлично“ һәм „яхшы“ билгеләренә тәгәлләделәр. Алар мәктәптә социалистик ярышны һәм җәмагат эшләрен оештыруда актив катнашалар. Комсомолецлар һәм пионерлар дәресләрне барлык укучыларның да „отлично“ һәм „яхшы“ үзләштерүләре өчен көрәшәләр.

Ләкин эштә зур кимчелекләр дә бар әле. Мәктәптә физкультура һәм хәрби белемне өйрәнү дәресләрен хәзерлеге җитәрлек булмаган укытучы алып бара. Физкультура залы җиһазландырылмаган. Мәктәп кирәкле дәреслекләр белән тәэмин ителмәгән. Бу кимчелекләрне тулысынча бетергәндә мәктәп үзенең алдынгылыгын киләчәктә дә саклап калыр.

Ә. Солтанов.

ЕЛКА ЯНЫНДА

Зур якты зал. Залның нак уртасында ям-яшел елка. Ул ерактан, кышкы күгелҗем урманнан балаларның шатлыклы елка бәйрәменә кунакка килгән. Балалар аны матур итеп бизәгәннәр, киендергәннәр. Аның энәләренә хисапсыз күп электр лампочкалары, ялтыравыклар, муенсалар асканнар, Ә нак очына кызыл канатлы самолет белән парашютчы кызны урнаштырганнар. Елка төбендә аппак киемнән мәһабәт зур сакаллы кыш бабай басып тора. Ул балаларга бик күп итеп яңа ел бүләкләре алып килгән...

Залда тәмле чыршы исе аңкый. Бу җәйге нарат урманын хәтерләтә. Оркестрдан чыккан шатлыклы марш бөтен залны яңгырата. Һәр кайда җанлылык, тантана. Бәйрәмчә киенгән, көләч йөзле, көр күңелле балалар төркеме арткannan-арта бара.

Менә кичә башланды. Балалар елка тирәсе буйлап әйләнергә, үзләренең матур яңгыравыклы тавышлары белән гүзәл елканы мактап җырларга керештеләр.

Гармончы „Кабардинка“ биү көен уйный башлады һәм елка тирәсен җинел атлап биючe балалар чолгап алды. Калганнар аларга кул чабып көч биреп тордылар. Аннан соң массовик җитәкчелегендә күмәкләп биюләр, массовый уеннар дәвам итте.

Балалар елкага кызыгып, үзләренең бәхетле тормышлары турында җырлап елка тирәсендә бик озак уйнадылар. Алар үзләренең иң матур җырларын балаларга бәхетле тормыш тудыручы кешегә—бөек Сталинга багышлап җырладылар. Шатлыкның иге-чиге булмады. Бер җыр икенче җыр белән, бер биү икенче биү белән алышынды, үзләренең һөнәрләрен күрсәтергә теләүчеләрнең саны арткannan-арта барды.

Менжинский исемендәге клубта елка кичәсе бик күңелле үтте. Балалар рәхәтләнеп, шатланышып күңел ачтылар. Татарстан Дәүләт Филармониясе һәм Татар Дәүләт Опера театры артистлары тарафыннан бирелгән концертны бик яратып тыңладылар. Соңыннан балаларга яңа ел бүләкләре өләшенде.

Р. Н.

КАЗАНДА А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Шушы көннәрдә Галактионов урамында („Динамо“ стадионы белән янәшә) элек Деренько булочные һәм пекарнясе булган йортта пролетариатның бөек язучысы Алексей Максимович Горький музей-йорты ачыла. Бу йортта 1885—86 нчы елларда А. М. Горький торган һәм подвалда урнашкан пекарнядә пекарь ярдәмчесе булып эшләгән.

Йорт элеккеге хәленә кайтарылды. Горькийның „Минем университетларым“ әсәрендә язылганча җиһазландырылды.

Йортның беренче катында музей залы урнашкан. Анда А. М. Горькийның Казандагы тормышы турындагы документлар, фото-рәсемнәр, скульптуралар куелган. Бер почмакта иске Казан күренеше һәм Горький яшәгән елларда Казан шәһәренең планы, Горькийның үзе тарафыннан Казан турында язылган сүзләре куелган. Шулай ук Горькийның Казанда яшәгән чорда укыган китапларыннан һәм аның беренче басылган әсәрләреннән витрина оештырылган. Экспонатлар арасында Горькийның тарихчы иптәш Калининга һәм башка кешеләргә язган хатлары, Горькийның маскасы һәм башкалар бар.

Музейгә куелган экспонатлар Горькийның Казан чорын яхшы ук тулы күрсәтәләр.

ОСОАВИАХИМ АКТИВИСТЛАРЫН БҮЛӘКЛӘҮ

Осоавиахимның Татарстан Үзәк Советы оборона эшендә актив катнашып эшләүчеләрдән 23 кешене „Активист“ значегы белән бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында запастагы командирлар, политработниклар һәм Осоавиахимның район Советы работниклары һәм башкалар бар.

БЕЛДЕРҮ

3 нче гыйнварда, кич 7 сәгаттә Казан Дәүләт Университетының актовый залында, Молотов районы өчен, „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы“, дигән темага лекция була. Лектор иптәш ГРОМОВ.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КОЛХОЗЛАРДА ВОДОПРОВОДЛАР

Чистай районының „Красный луговик“ һәм Ширәмәт районының „Свобода“ колхозларында водопровод салуга хәзерлек бара. Водопроводның проекты Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты янындагы фәнни-техника советы тарафыннан расланды.

Водопровод өчен су күтәрү башнялары төзеләчәк. Су чыгару өчен жил белән эшли торган двигательләр куела. „Красный луговик“ колхозындагы водопроводны салу өчен 50 мең сум расход тотылачак.

ДӘҮЛӘТНЕҢ ӨЧЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК ЗАЕМЫ

(БЕРЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГАРЫЛЫШЫ)

Процентсыз чыгарылышы буенча отышларның дүртенче тиражының белешмә таблицасы

Тираж 1939 нчы ел 23 һәм 24 нче декабрьдә Сталинабад шәһәрендә үткәрелде.

Тиражда 96.050.600 сумлык 610. 000 отыш уйналды.

Заемның процентсыз чыгарылышы буенча, 61 разрядның һәрберсенең, таблицада күрсәтелгән серия һәм облигация номерлары отты.

Облигациянең үз бәясе отыш сумасы эченә керә.

Отышлар түбәндәге серия һәм облигация номерларына чыкты:

Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме сумнар белән	Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме сумнар белән	Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме сумнар белән	Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме сумнар белән
40202	1—50	150	45182	02*)	500	48957	1—50	150	54314	21*)	500
40549	1—50	200	45223	32*)	500	49130	1—50	200	54393	1—50	150
40602	04*)	500	45414	47*)	500	49279	1—50	150	54576	1—50	150
40880	1—50	150	45428	1—50	150	49961	1—50	150	54841	1—50	150
40984	1—50	150	45483	1—50	150	49962	1—50	150	54946	1—50	150
41140	1—50	150	45589	1—50	150	49971	1—50	150	54971	09*)	500
41145	1—50	200	45611	1—50	150	50001	1—50	150	55143	05*)	1.000
41355	43*)	500	45643	09*)	500	50002	32*)	500	55154	24*)	500
41450	04*)	500	45672	1—50	150	50146	1—50	150	55361	1—50	150
41692	1—50	150	45718	1—50	150	50395	1—50	150	55419	1—50	150
41921	1—50	150	45764	37*)	500	50464	1—50	150	55481	1—50	200
42030	18*)	1.000	45826	20*)	500	50483	1—50	150	55574	1—50	150
42190	22*)	1.000	45848	1—50	150	50552	37*)	500	55826	1—50	150
42374	1—50	150	45920	1—50	150	50588	1—50	150	55855	1—50	150
42559	1—50	200	45981	1—50	150	50591	49*)	500	56052	1—50	150
42564	1—50	150	46333	30*)	500	50683	1—50	150	56160	26*)	500
42635	1—50	150	46495	29*)	500	50705	25*)	1.000	56165	23*)	500
42719	1—50	150	46526	1—50	150	50720	37*)	500	56172	1—50	150
42812	1—50	150	46578	1—50	150	51079	1—50	150	56206	1—50	150
42842	1—50	150	46583	1—50	150	51261	1—50	150	56407	1—50	150
42959	1—50	150	46609	1—50	200	51286	1—50	150	56703	08*)	500
42977	40*)	500	46634	28*)	500	51364	1—50	150	56719	1—50	150
43000	26*)	500	46687	1—50	150	51532	1—50	150	56872	1—50	200
43046	1—50	150	46738	1—50	150	51602	1—50	150	56888	27*)	500
43072	1—50	150	46786	1—50	150	51640	43*)	500	57014	1—50	150
43147	48*)	500	46876	1—50	150	51649	08*)	500	57020	30*)	1.000
43226	1—50	150	46959	41*)	500	51693	1—50	150	57090	01*)	500
43465	1—50	150	46990	1—50	150	51818	05*)	500	57276	1—50	150
43576	1—50	150	47028	1—50	150	51919	1—50	150	57313	1—50	150
43697	1—50	150	47075	34*)	500	52043	43*)	500	57568	46*)	500
43867	1—50	150	47160	1—50	150	52055	05*)	500	57606	29*)	500
44088	1—50	150	47175	1—50	150	52103	1—50	150	57616	12*)	500
44093	1—50	150	47217	1—50	150	52178	1—50	150	58028	1—50	150
44168	1—50	200	47247	1—50	150	52211	32*)	500	58191	1—50	150
44211	1—50	200	47308	1—50	150	52403	1—50	150	58270	12*)	500
44228	06*)	500	47634	1—50	150	52429	30*)	500	58330	1—50	200
44254	1—50	150	47693	45*)	500	52461	20*)	3.000	58387	1—50	150
44268	1—50	150	47730	1—50	200	52693	27*)	500	58394	1—50	150
44293	1—50	150	47833	1—50	150	52871	1—50	150	58438	1—50	150
44425	26*)	500	47885	1—50	150	52904	1—50	150	58491	1—50	200
44473	50*)	500	48112	1—50	150	52948	1—50	200	58615	30*)	500
44590	1—50	150	48397	1—50	150	52999	1—50	150	58642	1—50	150
44704	16*)	500	48440	1—50	150	53521	1—50	150	58707	1—50	150
44779	28*)	500				53595	22*)	500	58897	1—50	150
44811	1—50	150	48452	07*)	500	53725	1—50	150	59494	1—50	200
44815	1—50	150	48482	1—50	200	53752	1—50	150	59568	1—50	150
44833	1—50	150	48550	1—50	150	53814	1—50	200	59731	1—50	200
44878	1—50	150	48554	1—50	200	53851	1—50	150	59741	1—50	150
44915	1—50	150									
44978	1—50	200	48651	1—50	150	53896	1—50	150	59792	1—50	150
45025	1—50	150	48882	1—50	150	54048	1—50	200	59970	1—50	150

*) Бу серия облигацияләренең калган 49 номеры һәрберсе 150 шәр сум отты.

Издательство сотрудниклары коллективы һәм „Кызыл Татарстан“, „Красная Татария“ газеталары редакцияләренең сотрудниклары коллективы юрисконсульт

ВИКТОР ИВАНОВИЧ ГОРОЦКОЙ

ның кинәт үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм аның хатыны Евгения Николаевна Гороцкаяның кайгысын уртаклашалар. 1—1

В. И. ЛЕНИН МУЗЕЙ ЙОРТЫ

ремонттан соң, 1939 нчы елның 27 нче декабреннән башлап,

ҺӘР КӨН ИРТӘН 9 СӘГАТТӘН КӨНДЕЗ 3 КӘ КАДӘР АЧЫК

Музейне карарга теләгән барлык оешмаларның ул турыда заявкаларны алдан бирүләре сорала. Заявкаларны телефон буенча да бирергә мөмкин.

Экскурсия белән килүчеләргә махсус җитәкче бирелә. Музейгә керү һәр кем өчен түләүсез. Адрес: Казан, Ленин урамы, 58. Телефон 7—90. М—1

СССР НЕФТЬ ПРОМЫШЛЕННОСТЫ НАРКОМАТЫНЫҢ

Татарстан АССР Геолого-Разведка тресты,

Татарстан АССР да эшләү өчен, производстводан аерып укытып,

җир боғаулау буенча сменный һәм өлкән мастерлар хәзерләү өчен 4 айлык курсларга укучылар ала

Курсларга 18 дән 35 кә кадәр яштәге, кимендә 4 класс күләмендә белемле кешеләр алыналар. Курслар Шөгер район үзәгендә ачыла. Курсантларга айга 150 сум стипендия һәм тору урны бирелә,

Гаризалар 1940 нчы ел 10 нчы гыйнварга кадәр алына.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, белеме һәм сәламәтлеге турында белешмәләр һәм ике фотокарточка бирелергә тиеш.

Гаризаларны түбәндәге адреслар буенча җибәрергә: 1) Казан, Чернышевский урамы, 2, Татарстан Геолого-Разведка тресты. 2) Татарстан АССР Шөгер районы, Нефт эзләү группасы. Курсларга килү белән бәйләнгән расходлар түләнә. 2696—1

КОЛХОЗЛАР ИГТИБАРЫНА!

1939 нчы ел ноябрь аенда Татарстан АССР колхозларына, 1940 нчы елда колхозларда учет һәм хисапчылык эшләре өчен кирәкле кенәгәләр, бланклар комплекты һәм аларның бәясе күрсәтелгән почта переводы бланклары җибәрелгән иде.

Колхозларда учет һәм хисапчылык эшләре өчен кенәгәләр һәм бланклар комплектын күрсәткән бланклар алмаган колхозлар, ул бланкларны район җир бүлегеннән ала алалар.

Учет һәм хисапчылык эшләре формаларын алдыру өчен вактында подписка бирергә тәкъдим ителә.

Союзоргучетның Татарстан бүлеге.

2674—2—1

КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ БАЗАРЛАР ИДАРӘСЕ

Казан шәһәре базарларында ларекларлы, киоскылары, павильоннары булган барлык сәүдә оешмаларына 1940 нчы ел 10 нчы гыйнварга кадәр 1940 нчы ел өчен

ДОГОВОРЛАР ТӨЗЕРГӘ ТАКДИМ ИТӘ

Колхоз урамы, 1-15. Телефон 42—03.

Казан шәһәре базарлар идарәсе. 2071—1

„Казгорстрой“ трестының

МОНТАЖ КОНТОРАСЫ

яктырту һәм көч установкаларын җиһазлау, трансформатор пунктларын монтажлау, электродвигательләргә һәм электросварка трансформаторларына капиталь ремонт ясау буенча, заказчы материалы белән электромонтаж һәм механика эшләре үтәү өчен

ЗАКАЗЛАР АЛА

Казан, Киров һәм Париж Коммунасы урамнары чаты, 13/59.

2666—1 АДМИНИСТРАЦИЯ.

ЭНЕРГОСБЫТ

АБОНЕНТЛАРЫНА БЕЛДЕРӘ:

Реквизитлар (оешманың исме, расчетлар счеты номеры) үзгәрү булса, ул турыда тизлек белән Энергосбытка белдерергә тиеш.

Реквизитлар үзгәрү сәбәпле банкта булуы мөмкин булган аңлашылмаулыклар өчен җаваплылык абонент өстенә төшә. ЭНЕРГОСБЫТ.

2667—2—1

КИРӘК:

„Локомотив“ газетасы редакциясенә квалификацияле МАШИНИСТКА. Казан, Пионер урамы, 27. 2679—2—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы юллар идарәсенә, ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ һәм КАР БАСУДАН САКЛАНУ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Островский урамы, 2. 2695—2—1

Казан автомәктәбенә УКУ-УКЫТУ БҮЛЕГЕ ӨЧЕН МӨДИР һәм АВТО ЭШЛӘРЕ ТЕОРИЯСЕ БУЕНЧА УКЫТУЧЫЛАР. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Красный Химик урамы, 19. Мәктәп № 49. 2683—2—1

Ашханәләр трестына, ашыгыч рәвештә, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, ХИСАПЧЫЛАР, ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, СТАТИСТИКА БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, ДӘГВАЛАР БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕ БУХГАЛТЕР, КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ТЕХНИКАСЫ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР, КУЛИНАРИЯ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР-ТЕХНОЛОГ һәм ашханәләрдә эшләү өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Восстание бистәсе (Киров районы) Деловой урам. 2653—2—1

Казан Мехкомбинаты идарәсенә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ МАШИНИСТКАЛАР. Яңа бистә, Кызыл Татарстан урамы, 3, бүлмә № 13. 2652—2—1

Югары Волга Пароходчылыгының

КАЗАН ПРИСТЕНЕ

1940 нчы елның пароходлар йөрү сезонында су юлы белән, тиз йөртелергә тиешле йөкләрне ССР Союзының барлык урыннарына, ә нормаль тизлек белән йөртелергә тиешле йөкләрне Казан пристене районына кергән урыннарга йөртү буенча 1940 нчы елның 1 нче гыйнварыннан

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ БАШЛАДЫ

Договорлар төзү 1940 нчы ел 20 нче февральгә кадәр дәвам итә. Договор төзегән оешмаларның йөкләре беренче чиратта төялеп җибәреләчәк. Күрсәтелгән срокта договор төземәгән оешмалардан һичбер нинди дәгвалар алынмаячак.

2682—2—1 Дирекция.

Казан Авиация техникумының өйрәнү производство мастерскойларында „ГАЗ“ һәм „М—I“ маркалы

моторларга капиталь ремонт ясау буенча

ЗАКАЗЛАР АЛЫНА

Казан, Зур Красный урам, 58. 2616—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

3 һәм 4 нче гыйнварда

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Бүген талон 67.

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ

6 нчы һәм 12 нче гыйнварда көндезге спектакльләргә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Тулысынча яңа программа

Москва 4 нче труппасының гастрольләре.

ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ

Бөтен труппа катнаша.

Орденлы АЛЛИ-ВАД ның һәм ВЕРА МИРОВАНЫҢ соңгы гастрольләре.

1 нче гыйнвардан 12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгаттә, 2 сәгат 30 минутта һәм кич 8 дә

ЦИРК УЕННАРЫ

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЕЛЕКТРО“ 10, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез 10 сәгаттә ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ һәм башка сеансларда ЦИРК
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ДУСЛАР ЯҢАДАН ОЧРАШАЛАР Көндез 10 сәгаттә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 11, 1, 3, 5, 7-30 һәм 10 да	Көндезге сеансларда АЛТЫН АЧКЫЧ Кич БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе)
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	КУӘТЛЕ ТАШКЫН
„ПИОНЕР“ 6, 8 һәм 10 да	Көндез һәм кич ҺАВА ПОЧТАСЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс ВАРЯ КАПИТАН
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	СОРОЧИНСКАЯ ЯРМАРКА
„КОЛХОЗНИК“ 6, 8 һәм [illegible] да	УНӨЧ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР, № А — 2473. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 2.